СОҢГЫСЫ БУЛМАСЫН

Ялдан исән-сау әйләнеп кайту өчен, нәрсәләрне истә тотарга кирәк?

> 6

ЯШӘ ГЕНӘ

Акчаң җитсә, чыгымнар каплана

> 7

МАРАТ КӘБИРОВ:

«Зур һәм көчле милләтнең язучысы гына зур мәйданга чыга ала»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 91 (29058) | Җомга | 30 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

istockphoto.com/ru

ЯҢГЫР КӨТКӘНДӘ

БЫЕЛГЫ ҺАВА ТОРЫШЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНА ЗУР ЗЫЯН САЛА

Республиканың берничә районында корылык һавада гына түгел, туфракта да. Ике айда яңгыр нормасының нибары 10 проценты гына яуган. Кайбер районнарда узган елгы уңышның яртысына гына өметләнәләр. «Корылыгы гына булса, түзәр идек әле. Быелгы җәй көтелмәгән суыклары белән дә сынады. Шунлыктан күпьеллык үләннәргә зур зыян салынды», – ди аграрийлар. Игенчеләрнең дә, терлек тотучы халыкның да кәефе чамалы. Билләрне кысып бәйләргә туры килмәсме?

> 5

Ишетми калмагыз

М12 Мәскәү – Казан трассасының 70 проценты әзер. Бу хакта Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин «Автодор» компанияләр төркеменең күзәтчелек советы утырышында хәбәр итте.
Марат Хөснуллин сүзләренә караганда, 2023 елда кайбер юл объектларын ачу ниятләнә, шулар арасында аеруча әһәмиятлесе – М12 трассасының ике участогында хәрәкәтне башлап җибәрү. Арзамаска кадәр юлны – сентябрь башында, Казанга кадәрен декабрьдә ачу планлаштырыла. Шушы ук вакытка яңа юлда автомобильчеләргә комплекслы хезмәт күрсәтү һәм юл сервисын урнаштыру өчен 16 күпфункцияле зона эшли башлаячак.
«Автодор» дәүләт компаниясе идарәсе рәисе Вячеслав Петушенко сүзләренчә, М12 трассасы төзелешендә М11 һәм Үзәк боҗралы автомобиль юлы (ЦКАД) тәҗрибәсе файдаланылган. Бу юлларда шулай ук күпфункцияле зоналарны камилләштерү каралган. «Автодор» җитәкчесе әйтүенчә, М12 трассасының гамәлдәге 107 чакрымында өч күпфункцияле зона эшли. Ел азагына кадәр М12 трассасында ким дигәндә 14 шундый зонаны эшләтеп җибәрү каралган.

Тормыш иминлеге нигезләре (ОБЖ) фәнен Иминлек нигезләре һәм Ватанны саклау дип үзгәртергә җыеналар. Россия Мәгариф министрлыгы белдергәнчә, укучылар яңа программа буенча 2024 елның 1 сентябреннән укый башларга мөмкин.
Министрлыкның Гомуми белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәте һәм идарә департаменты директоры урынбасары Анна Тимофеева аңлатканча, бу җәһәттән укыту программасын булдыру буенча эшче төркем оештырылачак. Анда Оборона министрлыгы һәм Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы вәкилләре катнашачак. «Моның белән бергә без төп һәм урта мәктәпләр өчен яңа дәреслекләр әзерләү буенча эш алып барачакбыз», – дип билгеләп үтте Анна Тимофеева.

Илдә гомер озынлыгы 73,4 елга кадәр арткан. Бу хакта Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко хәбәр итте. Шулай итеп, ул пандемиягә кадәрге чор күрсәткечләреннән дә артып киткән.
Искәртеп үтик: апрель башында Татарстанның Министрлар Кабинеты 2025 елга республикада гомер озынлыгы 75,03 елга җитәр дип фаразлады.

Сезон башланганнан бирле, Татарстанның медицина оешмаларына, талпан кадалудан зыян күреп, 5834 кеше мөрәҗәгать иткән. Мөрәҗәгатьләр күрсәткече 100 мең кешегә 151,3 очракны тәшкил итә. Бу исә уртача күпьеллык дәрәҗәдән ике тапкыр күбрәк. Уртача күрсәткеч 75,7 булган.
Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсендә хәбәр итүләренчә, мөрәҗәгать итүчеләрнең 1497се – балалар. Узган елның шушы ук чорында 5356 талпан кадалу очрагы булган. Мөрәҗәгатьләр күрсәткече 100 мең кешегә 150,2не тәшкил иткән иде.

Районнарда ни хәлләр?

Мамадыш

Мамадыш районының Югары Кыерлы авылында Сабан туе 8 июль көнне узачак. Шул авылдан чыккан эшмәкәрләр, аны ел саен зурлап оештырып, авылдашларына бүләк ясый. Быел алар аны унбишенче тапкыр уздыра. Көн дәвамында мәйданда төркеме белән Илсөя Бадретдинова чыгыш ясаячак. Көрәш исә өч үлчәү категориясендә оештырыла: 60 килога кадәр, 60–85 кг һәм 85 килодан артык. Һәр категориядә беренче урын алучыга – 40000, икенче урынга – 25000, өченче урынга 15000 сум акчалата бүләк каралган. Баш батырга квадроцикл һәм тәкә бүләк итәчәкләр. Бәйрәм 12.00 сәгатьтә башлана.

Әлмәт

Әлмәтнең актив пенсионерлары, спорт мәйданчыгына чыгып, футбол буенча иң яхшы команда исеме өчен ярышты. Чара «Өченче буын» спартакиадасы кысасында узды. «Футбол ул – сәламәтлек, сәламәтлек ул – футбол», – ди спорт мәктәбе кырында узган турнирда катнашучылар. Алар арасында нефть тармагы ветераннары, «ТМС-групп», «Әлмәтнефть», «Татнефть-Добыча» оешмалары пенсионерлары, Эчке эшләр бүлеге ветераннары, шулай ук мәгариф системасы, «Тонус» клубы һәм Яңа Кәшер авыл җирлеге вәкилләре дә бар иде. Беренче урынны Урсалы футболчылары яулады, икенче урынны – «Альметьевскнефть» командасы, өченче урынны эчке эшләр бүлеге ветераннары командасы алды.
(«Әлмәт таңнары»)

Сарман

Әлмәт авылы мәктәбендә 12 елдан соң беренче чыгарылыш булды. «Сарман» кинотеатрында Морад Рәмзи исемендәге Әлмәт мәктәбен тәмамлаган биш укучыга урта белем аттестатлары тапшырылды. Ике егет, өч кызның шатлыгын уртаклашырга әти-әниләр, җитәкчеләр килгән иде. Мәктәп директоры Рамил Садыйков укучыларга хәерле юл теләде, төп белем документларын тапшырды.
(«Сарман»)

Чүпрәле

Яңа Чәке авылында мәчет булдыру турында бернечә елдан бирле сүз алып барыла. Ниһаять, быел әлеге эш башлана. Булачак мәчет шушы авылда туган, хәзерге көндә Иске Чүпрәледә гомер кичерүче Илдар Шәрәфетдинов йорты урынында булачак. Элек-электән үк шушы йортта, авыл картлары җыелышып, намаз укыган, дога кылган. Хәзер Илдарның әти-әнисе инде мәрхүмнәр, йорт буш тора. Авыл картлары, җыелышып, аны мәчет итеп үзгәртергә ниятләгән. Авыл халкы, иганәчеләр ярдәме белән монда төзекләндерү эшләре алып барылды. Шушы көннәрдә район мөхтәсибе Данир хәзрәт Шәрәфетдинов катнашында киңәшмә узды. Очрашу барышында бинаны төзекләндереп бетерү һәм мәчет итеп теркәү эшләрен төгәлләү мәсьәләләре каралды.
(«Туган як»)

ИТЕКЧЕДӘН СЫР ЯСАУЧЫ ТУАРМЫ?

Кукмарада бер, Чаллыда ике. Хөкүмәт йортында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге инвестицион совет утырышы узды. Анда республика районнарында яңа заводлар төзү тәкъдимнәрен дә җиткерделәр. Утырышта 10 миллиард сумлык тугыз проект хупланды.

Кукмарада сыр ясый башламакчылар әнә. Районның сөт комбинаты яңа завод төзү проектын тәкъдим итте. Тәүлегенә 500 тонна сөт эшкәртергә ниятлиләр. Район халкына эш тә, аш та булачак. Әйтүләренә караганда, сыр җитештерү өчен чималның 60 процентын Кукмара фермерларыннан алачаклар. Районда елына 1800 тонна сөт продукциясе җитештермәкчеләр. Яңа Кукмара бистәсендә урнашачак заводта 250 кешегә эш урыны булыр дип фаразлана. Инвестиция проектының бәясе – 3 миллиард сум.

Эшкуарларны исә «Дуслык»та көтәләр. Татарстанның Яшел Үзән районында әнә шул исемдәге индустриаль парк төзергә ниятлиләр. Яңа проектны утырышта «R1» компанияләр төркеме генераль директоры Дмитрий Реутт тәкъдим итте. Тура бистәсеннән ерак түгел урнашкан мәйданда кече һәм урта бизнес вәкилләре, зур предприятиеләр өчен сәнәгать бинналары төзү күздә тотыла. «Дуслык» үзе бер шәһәрчеккә дә әйләнмәгәе. Киләчәктә индустриаль парк территориясендә яшәү өчен бөтен уңайлыкларны булдырмакчылар. Яшел Үзән районына бәйле проектларның тагын берсен «ТИМФОС» компаниясе тәкъдим итте. Инвестор «Яшел Үзән» сәнәгать паркы хезмәткәрләренә кунакханә төземәкче. Дүрт катлы бина 200 урынга исәпләнгән.

> **Талия МИҢНУЛЛИНА,**
> **Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе:**
> – Яңа проектларның үзенчәлеге – эшче көчләр аз таләп ителүендә. Тугыз проектны тормышка ашыру өчен 2 меңгә якын яңа эш урыны кирәк булачак. Әмма безнең хезмәт базары өчен бу да күп әле. Татарстанда эшсезлек дәрәҗәсе ярты процепттан да кимрәк. Ягъни эшли алган бөтен кеше болай да мәшгуль, бездә хезмәт сөючән халык яши, артык кеше юк. Шуңа күрә мәсьәләне хәл итәргә кирәк. Мәсәлән, эшне автоматлаштырырга, Татарстанга эшкә илнең башка төбәкләреннән, ә бәлки чит илләрдән дә күченеп килсеннәр өчен, вакытлыча яки тулай тораклар төзергә мөмкин.

Утырышта «Түбән Кама» сәнәгать паркын үстерү турында сүз булды. Бу хакта әлеге территориянең идарәче компаниясе директоры Константин Пучин сөйләде. Аның әйтүенчә, бүген парк бар көченә эшли. Шуңа күрә дә аның өченче чиратын төзү юнәлешендә эш башланган. Ул 26,4 гектар мәйданда сафка басар дип көтелә. Биредә 12 компаниягә эш өчен тиешле шартлар тудырмакчылар. «Фаразланган инвестицияләрнең гомуми күләме 1 миллиард сумнан да артып китә, өстәмә рәвештә 300 эш урыны булдырылачак», – диделәр утырышта.

«Полюс» сәнәгать паркы идарәче компаниясе җитәкчесе Артем Ананченко да үсеш проектын тәкъдим итте. Яшел Үзән районындагы сәнәгать паркында бүген 4 резидент исәпләнә. Алар 300дән артык эш урыны булдырган. Территория тулы көченә эшли, аңа сорау да зур. Шуңа күрә сәнәгать паркын тагын да үстерергә телиләр.

Чаллы халкына да эш артмагае. Автокалада берьюлы ике завод төземәкчеләр. Беренчесен «ТЭСК» компаниясе сафка бастырырга тели. Утырышта Чаллыда асфальт-бетон заводы төзүгә бәйле проект тәкъдим иттеләр. Әзер чималны сатып алучылар да Татарстан юлчылары, аерым алганда, Кама агломерациясе оешмалары булыр дип көтелә. Икенче заводта исә нефть тармагы өчен кирәкле җиһазлар җитештермәкчеләр. «Каманефтемаш» компаниясе Чаллыда шул исәптән мобиль, стационар бораулау җайланмалары, скважина өчен кирәкле күтәрткечләр җыярга ниятли. Яңа заводта йөздән артык кеше эшләр дип фаразлана.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Күперне ныгытыр чак

Тагын да берләшер, хезмәттәшлекне ныгытыр чак. Россия һәм Белоруссия төбәкләренең X форумында бу фикер еш яңгырады. Уфада узган чарада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

Чара башланыр алдыннан, кунаклар конгресс-холл каршындагы мәйданчыкта Россия һәм Белорусссия төбәкләренең халык хуҗалыгы казанышларыннан торган күргәзмә белән танышa алды. Анда ике дәүләтнең 19 төбәгеннән 35 оешма эшләп чыгарган 100 төрдәге техника тәкъдим ителде. Күргәзмәне Россия Федераль Җыенының Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко да карады. Ул Татарстанның ике ил төбәкләре арасында хезмәттәшлекне үстерүгә зур өлеш кертүен билгеләп үтте.

Форум кысасында узган секция утырышында да яңгырады бу фикер. Анда катнашучылар ике дәүләт арасында төбәк һәм муниципалитетара хезмәттәшлек үсеше, тышкы көчләрнең тискәре йогынтысына каршы тору буенча өстәмә чаралар күрү, Россия һәм Белоруссияне алга таба ныгыту турында сөйләштеләр. Утырыш ахырында Балык Бистәсе районы белән Минск өлкәсенең Стародорожский районы арасында дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыру турында килешү имзаланды. Ике ил арасындагы район дәрәҗәсендәге беренче муниципалитетара килешү бу. Аның нигезендә район икътисадына инвестицияләр җәлеп итүдә ярдәм итү, мәгариф, мәдәният һәм спорт үсешендә, эшлыклар сәясәте, туризм, мәгълүматлаштыру һәм башка өлкәләрдә хезмәттәшлек итү күздә тотыла.

Билгеле булганча, Белоруссия – Татарстанның төп тышкы сәүдә хезмәттәшләренең берсе. Узган ел ике республика арасында товар әйләнеше 817,5 млн доллар тәшкил иткән. Күпьеллык хезмәттәшлек нәтиҗәсе бу, билгеле.

Форумның беренче көне йомгакларына нәтиҗә ясаганда моңа Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да игътибар итте.

– Безне сәүдә-икътисадый мөнәсәбәтләр генә берләштерми. Милли мәдәниятләрне саклау, мәгариф системасын үстерү, Союз дәүләте тарихын өйрәнү өлкәсендә дә уртаклыкларыбыз күп. Татарстан халыклары ассамблеясы да шушы мөһим максатларга хезмәт итә. Якшәмбе мәктәпләре, халык бәйрәмнәре аша ул республикада яшәүче белорусларның телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклап калырга ярдәм итә. Шул рәвешле Татарстанда яшәүче халыкларның да берберсенә якынайта, – диде парламент башлыгы.

Форум кысасындагы барлык очрашулар бүгенге вазгыятьтә хезмәттәшлеккә аяк чалган киртәләрне җиңәргә ярдәм итәчәк. Валентина Матвиенко чараның төп утырышында шулай дип белдерде.

– Бүген Россия белән Белоруссиянең барлык төбәкләре диярлек үзара хезмәттәшлекне җайга салды. Хәзерге санкция шартларында аеруча мөһим бу. Импорт алмаштыруның әһәмияте көннән-көн арта бара. Шуңа күрә төбәкара килешүләр безнең илләрнең икътисадый хезмәттәшлеген ныгытырга ярдәм итә. Машина төзелеше, нефть химиясе, төзелеш, транспорт, авыл хуҗалыгы тармагында эшләүче уртак оешмаларыбыз үсеше өчен яңа сулыш алды. Форум кысасындагы барлык очрашуларыбыз бу юнәлештәге бөтен проблемаларны җиңәргә ярдәм итәчәк, – диде Федерация Советы Рәисе.

Валентина Матвиенко Татарстанны Белоруссия белән иң актив хезмәттәшлек итүче төбәкләрнең берсе дип атады. Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, монда ун ел дәвамында үткәрелүче форумның да өлеше зур.

– Көнбатыш тарафыннан кертелгән чикләүләр шартларында Татарстан белән Белоруссия арасында хезмәттәшлек тагын да ныгыды. Импорт технологияләре белән компонентларын алыштыру өчен, барлык җитештерүчеләрнең көчләрен берләштерергә кирәк, – дип сөйләде Фәрит Мөхәммәтшин үз чыгышында. – Белорусь тракторын, комбайннарын сатып алудан тыш, авыл хуҗалыгы тармагында җитештерүчеләрнең фәнни яктан хезмәттәшлегә дә ныгый бара, селекция һәм орлыкландыруның яңа юллары эзләнә. Татарстанда Белоруссиядә эшләнгән автобус, трамвайлар да актив рәвештә кулланыла. Төгәлрәк әйтсәк, бүген Казан буйлап йөргән трамвайларның – 37 проценты, «МАЗ» автобусларының 50 проценты Белоруссиядә җыелган.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, форум кысаларындагы эшчәнлек хезмәттәшлекне тагын да ныгытачак, дип өметләнә.

– Форум барышындагы очрашу, сөйләшү, фикер алышулар нәтиҗәләре нигезендә төбәк арасындагы хезмәттәшлекне тагын да киңәйтәчәкбез. Инвестицияләр, мәдәни-гуманитар ярдәм юнәлешендә дә эшчәнлекне ныгытырга исәп. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Белоруссиядәге хезмәттәшләребез бик ышанычлы, алар төрле яклап үсештә. Татарстанда яшәүче белоруслар да безнең хезмәттәшлек үсешенә үз өлешен кертер дип өметләнәм, – ди Фәрит Мөхәммәтшин.

Киләсе елгы форум исә Белоруссиядә узачак.

Заман таләбенә җавап итеп...

«Татарстан – Яңа Гасыр» иҗтимагый-сәяси хәрәкәте оешу илдә-җирдә башланган зур үзгәрешләргә бәйле. Заман алышынганда җәмгыятьтә халыкны туплаучы бер көч кирәк иде. Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев тәкъдим иткән «Татарстан – Яңа Гасыр» хәрәкәте әнә шул көчкә әйләнде.

Социаль-икътисадый үзгәрешләр барганда кыйблаңы дөрес тоту өчен бик кирәк иде ул. Кичә хәрәкәт үзенең 10 нчы корылтаен уздырды. Парламентыбыз рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, «Татарстан – Яңа Гасыр» хәрәкәте хәзерге көндә дистәләрчә оешманы, 100 меңнән артык кешене берләштерә. Узган чирек гасырга якын вакыт эчендә әлеге хәрәкәт, алга куелган максатларга ирешү өчен, иҗтимагый мөмкинлекләрне барлау буенча зур тәҗрибә туплады, аның абруе елдан-ел күтәрелде, фикердәшләре артты.

«Татарстан – Яңа Гасыр» эшчәнлеге яшәешебезнең һәр өлкәсенә кагыла. Бу табигый да, чөнки әлеге хәрәкәт республикада яшәүче һәркемнең мәнфәгатьләрен чагылдыра. Фәрит Мөхәммәтшин халык белән эшләүне өстенлекле юнәлеш дип атады. Замана үзгәрешләренең хәрәкәт эшчәнлегенә нинди йогынты ясавын аерып әйтәсе килә. Украинада барган махсус хәрби операция безнең алга яңа таләпләр куйды. Илне, ватанны саклау идеясе көнүзәк мәсьәләгә әйләнде һәм халыкны бер максатка туплау кирәк иде. «Татарстан – Яңа Гасыр» бу эштән читтә калмады, әлбәттә. Операциядә катнашучыларга, аларның гаиләләренә ярдәм итү буенча Бөтенроссия акциясенә кушылып, «Ярдәм янәшә!» акциясен башлады. Хәрби операциядә катнашу өчен иреклеләрне туплау, алгы сызыктагыларга ярдәм итү, Россиягә кушылган яңа төбәкләрдә яшәүчеләргә булышу кебек эшләргә зур өлеш кертте.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтмешли, бүген хәрәкәт үз эшчәнлеген заман чакыруына җавап итеп башкара. Илнең иминлеген саклау, Татарстанны көндәшлеккә сәләтле көчле республика итүне үзенең олы бурычы дип саный.

Заманалар шактый авыр булуга карамастан, илкүләм проектлар эшли тора. Татарстан исә быел 29,3 миллиард сумлык 48 төбәк проектын тормышка ашырмакчы. Фәрит әфәнде фикеренчә, әлеге проектларның ничек эшләвен, аларның халык тормышын яхшыртуга нинди өлеш кертәчәген аңлатырга кирәк. Кыскасы, «Яңа Гасыр»ны алда яңача эшләүләр дә көтә әле. Әлеге хәрәкәткә хәер-фатиха биргән Минтимер ага Шәймиев исә «Татарстан – Яңа Гасыр»ның эшчәнлеген тагын да аныкларга, тәңгәлләштерергә киңәш итте.

Корылтайда иҗтимагый хәрәкәт җитәкчесе итеп янә Фәрит Мөхәммәтшин сайланды.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ДИПЛОМАТИЯ БӘЙРӘМЕ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Халыкара парламентаризм көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле татарстанлылар! Хезмәттәшләр – барлык дәрәҗәдәге вәкиллекле хакимият органнары депутатлары! Сезне чын күңелдән Халыкара парламентаризм көне белән котлыйм! Бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталар календарендә иң яшь бәйрәмнәрнең берсе булган бу көн парламент дипломатиясенең һәм парламентара хезмәттәшлекнең әһәмияттен ачык күрсәтә. Ул нәкъ менә Россия башлангычы белән гамәлгә куелды.

Бүгенге глобаль каршылык, туып килүче күпполярлы яшәеш шартларында мондый хезмәттәшлек уртак карашлар табуның, дәүләтләр мәнфәгатьләрен килештерүнең, гражданнар һәм читтә яшәүче ватандашлар хокукларын яклауның нәтиҗәле чарасы булып тора. Ул «Россия – Ислам дөньясы: Казан Форумы-2023» XIV Халыкара икътисадый форумында, бигрәк тә, аның парламентара өлешендә чагылыш тапты. Җыенның бу өлешенең максатлары – икътисадый һәм гуманитар хезмәттәшлекне киңәйтү, норматив базаны туры китерү юлларын карау, сайлаучыларның мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән килешүләрне парламент тарафыннан тикшереп тору.

Шушы максатларга ирешүгә саллы өлешне быел үзенең утыз еллык юбилеен билгеләп үтүче илебезнең парламент системасы – Россия Федерациясе Федераль Собраниесе, шулай ук төбәкләрдәге закон чыгаручылар һәм муниципаль вәкиллекле органнар да кертә. Нәкъ менә алар төрле дәрәҗәдә җәмгыятьнең хокукый нигезен булдыруда, территорияләр үсешенең стратегиясен һәм юнәлешләрен билгеләүдә, Россия Федерациясенең Тышкы сәясәте концепциясе нигезендә чит ил партнерлары белән хезмәттәшлек итүдә гаять зур роль уйный.

Хәзерге көндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы нормалар чыгаруда бай һәм уникаль тәҗрибәгә ия, ул төбәкләрдәге хезмәттәшләребезгә һәм федераль үзәккә дә бик кирәк. Гавами хакимиятнең нәтиҗәлелеген арттыруга, инновацион үсешкә һәм икътисадның конкурентлык сәләтен тәэмин итүгә, илебез товар җитештерүчесен яклауга һәм инвестицияләр җәлеп итүгә юнәлдерелгән йөзләрчә законнар кабул ителде. Гражданнарның социаль яклануын арттыруга, рухи яңарышка һәм республикада яшәүче халыкларның телләрен һәм мәдәниятләрен үстерүгә йөз тоткан программаларны аерым билгеләп үтәргә кирәк. Республика парламентының гамәлдәге парламентара килешүләр кысаларында чит ил партнерлары белән эшләве ышаныч һәм үзара аңлашу мохитен ныгытуга, төбәк дипломатиясенең куәтен ачып бирүгә, закон чыгару эшчәнлегенең рәвешләрен һәм механизмнарын камилләштерүгә ярдәм итә.

Хөрмәтле татарстанлылар! Халыкара парламентаризм көне – вәкиллекле халык хакимияте һәм көчле закон чыгару хакимияте идеяләренең тарафдарлары бәйрәме. Сезгә нык сәламәтлек, тынычлык, иминлек, актив гражданнар булуыгызны һәм эшләрегездә яңадан-яңа казанышлар телим! Ә депутат хезмәттәшләремә парламент эшчәнлегендә уңышлар, чөнки күпмилләтле Татарстанның, бөтен Россия Федерациясенең бүгенгесе һәм киләчәге күп очракта аларның эш нәтиҗәлелегенә һәм җаваплылыгына бәйле.

ЕЛАМАГАН БАЛАГА...

Чуаш, удмурт, мари, мордва халкы белән безне нәрсә берләштерә? Уртак Ватаныбыздан тыш, барыбызда да бер теләк: телне, гореф-гадәтләрне, гомумән, милләтне югалтмаска иде. Марат Әхмәтов сүзләре белән әйтсәк, татарларга бераз җиңелрәк, ә менә саны аз булган халыкларга тагын да күбрәк тырышырга кирәк. Аларны аеруча нәрсә борчый соң?

Бу сорауга җавапны Аксубайда Татарстанда яшәүче милләтләр вәкилләренең туган телләрен саклау мәсьәләләре буенча семинар-киңәшмәдә табарга тырыштык. Мондый чараның Чистайда узганы бар иде инде. Бу очрашулар нигә кирәк соң? Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе җитәкчесе Марат Әхмәтов сүзләреннән аңлашылганча, алар хакимият белән халык арасында үзенә күрә күпер сала, төрле милләт вәкилләренең ихтыяҗларын, теләк-тәкъдимнәрен тыңлау комиссиянең алдагы планын кузаллаарга ярдәм итә.

– Мари, удмурт, чуаш һәм мордва халыклары белән үзләре төпләнеп яши торган җирлекләрдә очрашабыз. Бу милләт вәкилләрен, аларның телләрен, гореф-гадәтләрен сакларга хакимият ничек итеп ярдәм итә ала? Менә шуны ачыклыйсы иде. Һәр милләт үзен үзе дә сакларга тиеш бит, уянып бетмәгәннәрне уятып булыр дип өметләнәбез, – диде комиссия җитәкчесе.

Татарстанда элек-электән гомер кичерүче милләт халыкларының хәлләре мактанырлык түгел. Беренчедән, татарлар гына түгел, сан ягыннан чуашлар да, удмуртлар да, марилар да, мордвалар да елдан-ел кими. 2010 ел белән чагыштырып, аерманы таблицадан күрә аласыз.

Милләтләр	2010 елдагы сан	2021 елгы җанисәп нәтиҗәләре буенча сан
чуашлар	160 мең	90 мең
удмуртлар	23 мең	21 мең
марилар	19 мең	16 мең
мордвалар	19 мең	12 мең

Башкаларның чыгышларын тыңлаганчы, комиссия җитәкчесе үз тәкъдимнәрен дә җиткерде. Әйтик, өч ел дәвамында «Татар сүзе» бәйгесе уздырыла. Бар да сүздән башлана, дигән кебек, шушындый ук бәйгеләрне башка телләргә дә багышларга була. Һәм кирәк тә, ди Марат Әхмәтов. Шуларны оештырырга кеше генә табылсын…

Утырышта милли мәгарифкә кагылышлы проблемалар да кат-кат телгә алынды. Шул ук дәресләкләр дисеңме, телне үзлектән өйрәнергә мөмкинлек бирә торган китаплар, махсус электрон чаралармы – барысы да мөһим. Шулай ук республика мәктәпләрендә чуаш, удмурт, мари һәм мордва телләренең 100 махсус сыйныфы бар.

– Аларны тагын да камилләштереп, тел өйрәнү өчен уңайлы мохит булдырырга ниләр җитми? Без барлык теләкләрегезне үтәргә әзер. Акча кызганмыйбыз, ул сыйныфларны алтынга төрергә әзер. Балалар бакчалары белән дә шул ук хәл, – диде бу җәһәттән Марат Әхмәтов.

Кызганыч, башка чыгыш ясаучылар, алда аталган проблемалардан читкәрәк китеп, күбесенчә үзләренең ничек яшәве, уздырган чаралары һәм бәйрәмнәре турында хисап тотты. Чыгышларның күбесе «Телне һәм милләтне без әнә шулай саклыйбыз» рухында булды. Алда саналган милләт телләрендә дәреслекләр булмавы, туган тел укытучылары җитмәве кайбер чыгышларда гына телгә алынды. Татарстанның чуаш милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе урынбасары Константин Малышев: «Безгә менә шундый китап кирәк иде», – дип, конкрет үтенечен дә җиткерде. Әмма проблемалар турында фикер алышу барыбер дә җитмәде. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының Милли мәгариф идарәсе җитәкчесе Илгиз Халиков та «Еламаган балага имчәк каптырмыйлар» мәкален искә төшерде.

«Татар-информ»

– Беренче чиратта, район башлыкларыннан яңа кадрлар әзерләү мәсьәләсен контрольгә алуларын сорыйбыз. Туган телләрдән имтихан биргән балалар белән эшләргә кирәк. Аларны укыту, соңыннан районга кайтару җаен карарга. Тел өйрәнү буенча электрон ресурсларга килгәндә, милли республикалар белән берлектә эшләргә була. Бу өлкәдә Башкортстанның тәҗрибәсен аерып әйтер идем. Аннан соң, булган мөмкинлекләрдән дә файдаланырга кирәк. Без очрашып торабыз, күп нәрсәне үзебез тәкъдим итәбез. Ләкин үзегезгә дә сорарга, тәкъдим итәргә кирәк, – диде ул.

Марат Әхмәтов исә район башлыкларына булган проблемаларны янә бер кат барлап, хисап тапшыру өчен бер айлап вакыт бирде.

– Тәге яисә бу милләт вәкилләре күпләп яши торган авылларга, милли мәктәпләргә, балалар бакчаларына чыгып, актив халык белән фикер алышып, булган кимчелекле якларны барласагыз иде. Аннары республика дәрәҗәсендә хәл итәр идек. Без моңа игътибар итми кала алмыйбыз, – диде ул, утырышны йомгаклап.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Әйтеп кенә бактым

Сез җүләр мәллә?

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Олыгайган саен балачакка кайту табигый инде ул. Шунысы кызык: балачак белән бергә авыл кешеләренең үзенчәлекле сөйләм теле, кызык гадәтләре дә искә төшә. Безнең авылда җөмлә төзүгә, берәр мәгънәле сүз әйтүгә бик иҗади якын килүчеләр иде. Ул кушамат чыгарулар турында әйтеп тә торасы юк, кешенең тышкы кыяфәтендәме, үз-үзен тотышындамы, берәр үзенчәлекне җәлт кенә тотып алалар да кушамат чәпәп тә куялар. Безнең авылның «Ленинбаш»лы малае да, «Изге»се дә, хәтта «Путин»ы да бар иде. Читтән килгән колхоз рәисен бик булдыклы булганга һәм йөз чалымнары бик охшаганга «Путин» дип кенә йөртә башладылар. Шулай дип йөртә торгач, үзенең исемен дә онытттылар.

Безнең авыл кешеләрен хәтта Татарстан радиосыннан да кушаматлары белән атаганнар. Моны балачакта безгә Аю Мансур сөйләде. Укытучы иде ул. Авылларга радио керә генә башлаган чак бу. Тик «техника казанышы»н халык төрлечә кабул итә: бер гади генә кара тәлинкә кеше булып сөйләсен әле! Җитмәсә, җыр, гармун тавышлары да яңгырап тора. Дини фанатиклар, тәлинкә эченә җен оялаган, дип, өйгә радио керттермәскә куша. Шуннан соң авылда иң акыллы саналган Ленинбаш Сәйфине Казанга, радиога җибәрәләр. Икенче көнне өйлә вакытында кара тәлинкәдән моңын тавышы ишетелмәсенме?! «Әй, Субаш Аты кешеләре, особенны Таз Тәлгать, Бүре Гайние, Кәтүк Сабир, Кетер Сәләхи! Бу – мин, авылдашыгыз Ленинбаш Сәйфи булам. Кара тәлинкәгә җен оялмаганга ышандыгызмы инде? Ышансагыз, вәт шул... Иртәгә иртүк кайтырга чыгам, мәгәрич – Кәтүк Сабирдан. Иң күп кыткылдап йөрүче шул иде. Мәгәричеңне әзерлә, Кәтүк Сабир!»

Ленинбаш Сәйфи тагын ниләр сөйләгәндер, билгесез. Әмма шул хәлдән соң аның кушаматын бик тиз генә, үзе кайтып җиткәнче үк «Мәгәрич Сәйфи»гә алыштырып та куялар.

Торам-торам да шаклар катам мин авылдашларга. Алар телендә «җүләр», «дивана», «тиле» кебек сүзләр дә еш кына иркәләү сүзе кебек кулланылды. Хәтта әтием дә әнигә еш кына: «Әй, тиле күкем», – дип әйтер иде. Минем дә кайчак хатынымны кочаклап: «Җүләркәем минем!» – дип әйтүем дә шул авыл тәрбиясе инде.

Хәтта сеңлем Гүзәлнең улы – Диасның теле дә безнең авыл сөйләме белән ачылды бугай. Җәй көне бөтен шәһәр баласы авылга кайта бит инде ул. Диасның да бөтен җәе авылда узды. Әти-әни янына кайткан саен Диас белән гәпләшә идек без. Берсендә хатыным моңа шаяртыпниндидер сүз әйткән дә, Диас, бик җитди кыяфәт чыгарып: «Фәридә апа, син җүләр мәллә?» – дип куйган. Көлешә-көлешә егылып китә яздык, дүрт яшьлек бала шулай дип әйтсен әле! Безнең авыл кешеләре бер үк сүзгә әллә нинди мәгънә төсмерләре сала беләләр иде. Мин аларның теге яки бу сүзне яратыпмы, ачуланыпмы, иркәләпме, гаҗәпләнепме әйтүләрен интонацияләреннән генә аера идем. Хәтта «дивана», «тиле» кебек сүзләрне дә ярату сүзе кебек әйтүчеләр бар иде бездә. Авыл халкы «тел гыйлеме» дигәннең ни икәнен дә белмәгән, әмма үзенең образлы сөйләмен еллар буе камилләштерә, сүз байлыгын арттыра килгән. Авылда, алай гына да түгел, илдә-җирдә барган һәр вакыйгага үз теле белән аңлатма, бәя бирә килгән ул.

Кызык, бүген авылым кешеләре Украинада барган вакыйгалар турында ниләр уйлый, ничегрәк сөйли икән? Көнбатыш сәясәтчеләренең бүген безне фашизмда гаепләүләре турында ишеттеләр микән? Фашизмга каршы сугышта 27 миллион кешесен югалткан илдә фашистик идеология барлыкка килә алу авылдашларымның башына сыя микән?

Бу хакта сүз кузгатсам, ниләр әйтерләр икән? Түбән оч Фагыйлә апа, исән булса, дөнья бутаучылар турында: «Кирле-худлы сөйләп йөрмәсеннәр оятсыз кричләр», – дияр иде, мөгаен. «Худлы» урынына башка сүз әйтә иде ул, мин газетага язу килешмәс, дип ул әйткәнчә язмадым. Фагыйлә апага кушылып «шыр диваналар», «дөнья җүләре» дип әйтүчеләр дә табылыр иде... Ярый, күрәзәлек итмим, бу көннәрдә туган якларга кайтасым бар. Авылым урамнарын урармын, авылдашларымның хәлләрен сорашырмын һәм Украина, гомумән, дөнья хәлләре, фашизм турында сүз катармын, әйткәннәрен укучыларыбызга да җиткерермен.

ҮЗӘК БАНК КАТЫ ТОРА, ӘММА...

ЯКИ ДӨЯНЕҢ СЫРТЫН СЫНДЫРГАН САЛАМ БӨРТЕГЕ

Ялланган сугышчылар фетнәсе аздан гына Россиянең финанс кырында зур давыл китереп чыгармады. Гыйсъянчылар маршы әле ярый ял көненә туры килде һәм кыска вакытлы булды. Югыйсә рекордлы сум түнтәрелеше һәм базар паникасы китереп чыгара ала иде. Доллар болай да кушаяклап сикерде. Инде тынычлык урнашкач та, 87 сумнан югарырак үрне яулады, ә фетнәле ял көннәрендә валютаны өч урыны саннан торган курстан алучылар да булды, диделәр. Самолет билетларының бәясе дә күккә ашты. Давылдан качу өчен, чит илләргә 300 мең сумга билет алучылар да байтак булды. Әмма дүшәмбе көнне экспортлаучылар, базарга зур күләмдә валюта чыгарып, тотрыклылыкны кире кайтардылар.

Финанс тотрыклылыгын саклау Россия өчен гадәттән тыш зур актуальлеккә ия. Инфляция һәм девальвация хәзер шундый ноктада: аларның үсеше зур каңгатьсезлек тудыра ала. Каңгатьсезлек фетнә өчен туфрак буларак хезмәт итәчәк. Бер Россия өчен генә түгел, дөньяның барлык илләре өчен дә шулай бу. Шуңа күрә Халыкара хисаплар ясау банкы (Банк международных расчетов (БМР) милли банклардан акча-кредит сәясәтен кырысландыруны таләп итә. Санкцияләр санкцияләр белән, ә бизнес һәм финанслар һәрвакытта да интернациональ алар. Россия Үзәк банкы шуңа күрә глобаль банклар киңәшен үтәргә тырыша. Финанс өлкәсендә кырыс сәясәт бер генә нәрсәне күз алдында тота: процент ставкасын югары күтәрәсең. Шулай эшләгәч, кредит алу кыенлаша, бурычка кыйммәтле товарлар сатып алу кими, бу инфляцияне авызлыклый дип санала. Халык акчасын, зур процентлар вәгъдә иткәнгә күрә, банк депозитларына илтә, товарларга тотмый. Монысы да – бәя күтәрелүгә каршы чара. Әмма аңлый торгансыздыр инде: җитештерү чүгә андый шартларда. Шуңа күрә Үзәк банк белән Хөкүмәт бу мәсьәләдә һәрвакыт конфликтта булалар.

Россия Үзәк банкы глобаль финанс мафиясенең күрсәтмәләрен арттырып үти хәзерге көндә. Рәсми инфляция 2,5 процент кына булып санала, ә төп ставка аннан өч тапкыр югарырак – 7,5 процент. Россия финанс аналитиклары, Үзәк банк үз сәясәтен үткәрсен, көнбатышлыларга карамасын иде, дигән теләк белдерәләр. Сәясәтне ничек кенә корсаң да, бер үк тозакка килеп кабасың ләкин. Арзанлы кредитны күп итеп өләшеп икътисадны җанландырырга була, әмма киләчәктә банкротлар парады вәгъдә итә. Кредитны кыйммәтләндереп (ставканы күтәрү аша), инфляцияне йөгәнләргә була, әмма җитештерү кризисы көн тәртибенә килеп баса һәм барысы да яңадан кабатлана.

Россиядә агымдагы вазгыять үк шуны күрсәтә: кредит карталары буенча бурычлар тарихи рекордны яулый. Май ае нәтиҗәләре буенча түләнмәгән бурычлар күләме 225 миллиард сумга җиткән. Бу барлык кредитлар күләменең 12 проценты икән. Майда банклар россиялеләргә 2,105 миллион кредит картасы өләшкәннәр. Ул карталарда 194,33 миллиард сум акча булган. Түләнмәгән бурычлар саны исә 9 процентка үскән. Өләшенгән кредитларны җыеп алу катлаулы мәсьәләгә әйләнәчәк дигәнне аңлата бу. Халыкның матди хәле бик үк шәп түгел дигән мәгънә дә укый алабыз саннардан.

Үзәк банкның кредитлауны авызлыклап торырга тырышуы аңлаешлы шуңа күрә. Ләкин финанс регуляторы күпме генә тырышмасын, илдә кредитлау барыбер рекордлы темплар белән үсуен дәвам итә. Белгечләр Россиядә рекордлы кредит бумы күзәтәләр. Май аенда физик затларны кредитлау тарихта булмаганча 583 миллиард сумга үскән. Гыйнвар – май күрсәткече шулай ук рекордлы – 1,96 триллион сум. Ипотека кредиты да рекорд куйган: айга 332 миллиард сумга арткан. Торак базарында бәяләр болай да болытлардан өстә йөзә, тагын да югарырак күтәрелэчәк, димәк. Автокредитлар да бәйдән ычкынган: майда 38 миллиард сумга җитеп, тарихи рекорд куйганнар.

Икенче яртыеллыкта Үзәк банкның акча – кредит сәясәтен катыландыруы нәтиҗәсендә бурычка акча бирү кимер дип көтәләр. Риэлторлар, мәсәлән, торак сатып алучыларга бераз көтәргә киңәш итә. Кредитлау кимесә, фатир бәяләре төшмәсме дип өметләнәләр. Кредитка фатир сатып алу мөмкинлеге булучылар саны да бик кимегән дип әйтәләр. Әмма халык мөмкинлеккә карап тормый, әҗәт җыя. Ипотека процентын күтәрүгә хөкүмәт каршы тора. Моңарчы өстенлекле ипотека аша торак базарын җанландырып торырга тырыштылар. Тик соңгы көннәрдә Финанс министрлыгы өстенлекле ипотеканың бюджетка каты суга башлавына игътибар итте. Хөкүмәт көткәнгә караганда күбрәк өстенлекле кредит бирелә. 2023–2025 елларга бюджеттан өстәмә 171,5 миллиард сум акча түләргә туры киләчәк икән бу максатка. Финанс министрлыгында хәзер баш кашыйлар: дәүләтнең акчасы җитмәячәк, диләр. 2023 елның биш аенда гына да өстенлекле кредит бирү 1,217 триллион сумга җиткән. Бу үткән елның шул чоры белән чагыштырганда 73 процентка күбрәк. Кредитлау мондый темплар белән дәвам итсә, без, бердән, торак бәяләренең яңа рекордын күрәчәкбез, икенчедән, бурычны кайтарып бирү мөмкинлеген югалтучылар саны артачак, өченчедән, бюджетның, авызын ачса, үпкәсе күренә башламагае... Ипотеканы кискен кимету дә торак төзелешен аяктан егачак. Шуңа күрә хөкүмәтнең финанс блогы белән реаль икътисад тармагын җитәкләүче министрлар бу мәсьәләдә капма-каршы сәясәт үткәрергә тырышачаклар. Үзәк банк ипотеканың чүпрә кебек кабаруына беренчел взносны кискен күтәреп каршы торырга ниятли. Процентларны льгота белән субсидияләү дәвам итә, чөнки хөкүмәт финанслый, әмма беренче взноска акча табу авыр мәсьәләгә әверелачәк. Бу сәясәт кая кадәр алып барыр, анысын икенче яртыеллыкта күрербез, Аллаһ теләсә.

Россиядә икътисад законнары үзләрен сәеррәк тоталар бит. Аномаль зонадагы кебек. Инфляциянең түбән күрсәткечә якын киләчәктә югарыга үрләгән бәяләр булып үзгәрер, диләр. Үзәк банк күптән инфляция көтә инде. Бу юлы бензин бәяләре әскә күтәрелү инфляцияне югарыга тартыр дип фаразлыйлар. Икътисад законнары буенча ягулыкка бәяләр төшәргә тиеш, әмма бензин да, дизель дә кыйммәтләнә. Ваклап сату бәясе атна саен үсә, бу – факт. Июнь башыннан литры ике сумга кыйммәтләнде, диләр. Газета хәбәрчесе бәяләр үсешен чагыштырырга дип рәсми таблицаларны ачкан иде, алар 13–19 март атнасында катып калганнар. Без кышкы якта ук бензинга бәяләр артасын фаразлап: «Ягулык дефициты булмасын өчен, бәяләрне кискен күтәрү ихтыяҗы туачак», – дип язган идек, шул вазгыять тормышка ашып бара. Ягулыкны күпләп сату бәясе биржаларда, без фаразлаганча, кискен үсте, ел башыннан уртача 40–50 процентка күтәрелде. Ваклап сату бәясен демпфер – хөкүмәтнең нефтьчеләрне субсидияләве тотып торды. Хәзер, бюджет капчыгы резиннан түгел дип, хөкүмәт демпфер субсидия күләмен киметергә җыена. Июль башыннан алып 2024 елның июленә кадәр демпфер күләмен ике тапкыр киметергә телиләр. Бу бюджетка ай саен 30 миллиард сум акчаны янга калдырырга булышачак. Димәк, безне июльдән ягулык бәясенә бәяләрнең яңа үсеше көтә. Мотор ягулыгы машиналы гына түгел, икътисадны да әйләндерә, ул кыйммәтләнсә, көндәлек куллану товарлары да бәя өстәячәкләр. Рәсми фаразлар шундый.

Үзәк банк менә шуңа күрә төп ставканы рәсми инфляциядән югарырак тота да инде. Күрәбез, бик булышмый. Илдә чуалышлар һәм болганчыклык булмаса, бәяләр акрын гына үсәчәк. Мәйданга, патриотлык битлеге киеп, тагын берәр фетнәче чыкса, зур болганчыклык башланып, бар нәрсәнең асты-өскә килергә дә мөмкин. Әйтик, валюта курсы гына үссә дә, импорт товарларга бәяләр артачак бит. Бәяләр үсешен без утыз елдан артык күзәтәбез инде. Шуңа күрә агымдагы үсешкә исебез китми. Аны санкцияләр нәтиҗәсе дип аңламыйбыз.

Процент ставкасын күтәреп кенә кризис авызын томалап булмый. Кредитка акча өләшеп тә проблемалар хәл ителми. Өсте-өстенә өелгән проблемаларның берсе – бәлки артык зур булып та тоелмаганы дөянең сыртын сындырган салам бөртеге ролен үтәячәк. Үткән елларда өермә кебек узган Пригожин фетнәсе безгә шуны исбатлап күрсәтте. Хосусый хәрби компанияләр тудырган проблемалар өсте-өстенә өелделәр дә фетнә булып аваз салдылар. Россиядә шундый хәл булыр дип әйтсәң, кеше ышанмаслык иде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЯҢГЫР КӨТКӘНДӘ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ел елга охшамый

Татарстанда корылык хөкем сөрүен синоптиклар да раслады. КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы мөдире, профессор Юрий Переведенцев сүзләренчә, климат үзгәреше аркасында, республикада корылык елдан-ел күзәтеләчәк. 2010, 2021 һәм 2023 еллар очраклылык кына түгел, ә закончалык, ди белгеч.

– Игеннәр өчен яңгыр майда һәм июньдә аеруча кирәк. Ләкин быел явым-төшем апрельдә дә, майда да, июньдә дә булмады. Әйтик, майда ул норма буенча 39 мм буласы иде, тик 26 мм гына явып узды. Июньне дә шомлапып көтеп алдык. Бу айда 68 мм явым-төшем буласы иде. Тик ул республика буенча уртача 10 миллиметрга (норманың 30 проценты) да тулмады. Мин аграрийлар белән һәрдаим элемтәдә булгач, аларның кәефләрен яхшы аңлыйм. Аларга бер дә җиңел түгел. Явым-төшем булмау – авыл хуҗалыгы өчен критик хәл. Алдагы көннәрдә дә яңгырлар күренми, аның аравы эсселек килә, – диде Юрий Переведенцев.

Чирмешән, Сарман һәм Тукай районнарында хәл тагын да катлаулырак: анда 15 апрельдән 20 июньгә кадәр нибары 5,8 һәм 8,5 мм явым-төшем булган. Азнакай, Минзәлә, Әлмәт, Баулы, Мөслим районнарында корылык һавада да, туфракта да сизелә.

Гомумән алганда, быел республиканың күпчелек районнарында хәлләр катлаулы. Әйтик, Азнакай районында беренчеләрдән булып туфракта корылык игълан ителде.

– 8 апрельдә чәчүгә чыккан идек. Шул вакыттан бирле районда уртача алганда 19 мм яңгыр яуды, – диде районның авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Рамил Исламов. – Кайбер авылларда (Карамалы, Таллы Буләк авыл җирлекләре) явым-төшем нибары 9 мм гына төште. Майдагы суыклар күпьеллык үләннәрнең барысын да диярлек өшетте, шуңа күрә беренче чабуда уңыш бөтенләй булмады диярлек.

Татарстанның кайсы районнарында явым-төшем аеруча аз?

Районнар	Быелның 15 апреленнән 28 июненә кадәр булган явым-төшем, мм
Чирмешән	5
Сарман	8
Тукай	9
Кукмара	10,6
Түбән Кама	13
Тәтеш	15,2
Лениногорск	16,2
Зәй	17
Ютазы	17
Алабуга	17
Азнакай	19
Мөслим	20
Әтнә	20
Әгерҗе	21
Минзәлә	23

Яңгыр күп яуган районнар

Районнар	Быелның 15 апреленнән 28 июненә кадәр булган явым-төшем, мм
Арча	57,4
Нурлат	55,1
Яшел Үзән	53,7
Чүпрәле	52

*Мәгълүматлар республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан алынды.

tatarstan.ru

Бүген берьеллык үләннәр җитешеп килә. Яңгыр яуса, аңа һәм кукурузга өмет баглыйбыз. Ләкин аларга да дым кирәк.

Терлек азыгын әзерләү буенча да район иң арттა бара. Әлегә күпьеллык үлән чәчелгән мәйданнарның 43 проценты урылган, тагын 30–40 процент мәйданнарны кырау суккан. Нәтиҗәдә башка еллардагы 25–30 мең тонна урынына әлегә нибары 7 мең тонна сенаж әзерләнгән.

– Терлек азыгын башка төбәкләрдән алып кайтмыйча булмас. Инде сөйләшүләр башланды. Тик моның өчен хуҗалыкларның да финанс мөмкинлеге булу кирәк. Сөт бәяләре төшү дә авырлык тудырды. Фураж өчен курыкмыйбыз. Узган елдагы запас та бар. Арпа бәясе берaз күтәрелә башлады: 8,50 сум тора. Ләкин ашлык бәяләре быел әллә ни артыр дип уйламыйм, чөнки үзебездә дә, Россиянең башка төбәкләрендә дә ашлык запасы бар. Ә менә печән бәяләре югары булыр быел, – диде Рамил Исламов.

Идарә башлыгы әйтүенчә, шәхси хуҗалыклар да игътибардан читтә калмаячак. Азнакай районында корылык һавада да, туфракта да бар. Ягъни мондый корылык вакытында үсемлекләр дымны тамырдан ала алмый, димәк, яңа технологияләр кулланып, культураларны яфрактан тукландырырга кирәк.

Корылык ике-өч ел саен кабатлануны искә алып, алдан чаралар күреләме?

– Эшләргә өйрәнеп киләбез инде, – диде безнең сорауга җавап итеп Рамил Исламов. – 2010 елгы корылыктан соң яфрактан тукландыруга ныклап торып алындык. Әлегә шул гына тота да инде. Быел корылык кына булса, ерып чыгасы идек. Ләкин ике тапкыр китереп суккан суыклар күпьеллык үләннәргә зур зыян салды. Мондый хәл 2010 елда да, 2021 елда да булмады. 12 градус салкыннан соң корылык китте бит. Мондый хәлнең моңарчы булганы юк иде. Ләкин узган елгы запаслар белән ерып чыгарбыз дип уйлыйм.

Булганына өмет аз

Республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белгечләре фикеренчә, корылыкның уңышка тәэсире булмый калмаячак, әлбәттә. Алдан фаразларга яратмасалар да, узган елгы уңышны алып булмаячагы көн кебек ачык. Бүгенгә иң мөһиме – терлекләргә җитәрлек күләмдә азык туплап калу. Тик әлегә көнчыгыш районнарда терлек азыгы кытлыгы аеруча нык сизелә.

– Бүген безнең кырлардан күпьеллык үләннәрнең 80 проценты җыеп алынды. Ләкин без шушы мәйданнардан терлек азыгын 15 процент кына әзерли алдык. Май суыклары Актаныш, Азнакай, Әлмәт, Бөгелмә районнарына бик нык тәэсир итте. Күпьеллык үләннәргә үсәргә мөмкинчелек бирмәде. Бу районнарда беренче кат печән чабу булмады. Алдагы көннәрдә дә яңгырлар күренми. Шуңа күрә икенче чабуга да өмет зурдан түгел. Бар ышаныч кукурузга. Аннан яхшы уңыш ала алсак, зур күләмдә сенаж тутырып калырга планлаштырабыз. Бөтен өмет яңгырда, – диде министр урынбасары Марсель Мәхмүтов.

Җитәкче әйтүенчә, хуҗалыкларда узган елгы запаслар да күп түгел. Кайбер хуҗалыкларда ул 1–2 айга гына җитәрлек. Әйтик, Чирмешән, Югары Ослан, Яшел Үзән, Баулы, Спас, Менделеевск районнарында былтыргы запас аз. Бу районнарда ризык туплау өчен тагын да тырышыбрак эшләргә туры киләчәк. Шәхси хуҗалыкларга килгәндә, Кукмара, Арча, Нурлат районнарында шәхси хуҗалыкларга азык әзерләү өчен бик тырышалар, запас туплыйлар.

Вазгыятьне искә алып, министрлык район, идарә җитәкчеләре белән һәрдаим элемтәдә тора.

– Шәхси хуҗалыкларда да, эре хуҗалыкларда да хайваннарны, аларның продуктивлыгын саклап калырга тырышырга кирәк. Төп игътибарны шуңа бирәбез. Бүген үзебезгә генә өметләнмичә, күрше төбәкләрдән дә терлек азыгын белешергә кирәк. Бәлки чабып, сатып алырга мөмкинлекләр булыр. Кыскасы, ризык әзерләү буенча нинди мөмкинлек бар, барысын да кулланырга туры киләчәк, – диде Марсель Мәхмүтов.

Күңел борчулы

Корылык, суыклар эре хуҗалыкларны, фермерларны гына түгел, халыкны да сынады. Июньнең беренче яртысындагы кыраулар Әгерҗе, Актаныш, Биектау, Минзәлә, Азнакай һәм тагын берничә район кешеләренең бәрәңгеләрен, яшелчәләрен өшетте. Биектау районының Татар Урмады авылы халкы да ул вакытта шактый зыян күргән иде. Шушы авылда яшәүче Рамил Гыйльмановка шалтыратып, хәлләрен белешеп алдык.

– Ул вакытта без 10–15 мең сумга су сиптергеч сатып алып, өшегән бәрәңгеләргә күп итеп су сиптереп тордык. Шуның файдасы булды. Сабаклар яшәреп, матураеп киттеләр, инде чәчәк атарга җыеналар. Ә менә су сиптермәгән кешеләр бәрәңгесез калды быел. Кайберәүләрнең кабак, ташкабакларын да кырау сукты, – диде ул.

Ә менә Актаныш районының Теләкәй авылы халкы суыкларга каршы үз чаралары белән көрәшкән. Бакча башларында саклап торып салам яккан алар. Аннан килгән төтен бәрәңгене һәм яшелчәләрне саклап калырга ярдәм иткән. Тик шушы ук районның Аеш авылындагы хуҗалыкларга шактый зыян килгән.

– Июньнең беренче декадасындагы салкыннар кайбер кешеләрнең бәрәңге, кабак һәм башка яшелчәләренә зыян китергән. Кайберәүләр бәрәңгеләрен кабаттан утыртканнар. Безнең үзебезнеке алай ук куркыныч булмады, – диде Сәрмәдия Йосыпова. – Ләкин виноград, крыжовник, абрикос, груша, черешня агачларын, роза, гортензия кебек чәчәкләрне өшетте, корыдылар... Соң елгасы буенда юкә агачларының чәчәкләре юк, урыны-урыны белән басулар каралган. Аның өстенә корылык, яңгырлар юк, болыннар көеп бетте, көтүдәге малларга ашарга үлән юк. Кешеләрнең дә кәефләре ничектер борчулы шикелле. Ирем Корбан гаетенә мәчеткә барган иде. Анда «Нигез» хуҗалыгы җитәкчесе бер дә күңелле фаразлар әйтмәгән. Терлекләргә ризык әзерләүдә алдан хәстәрләгән күрә башлагыз, бер дә яхшы ел килергә охшамаган, дип әйткән. Ни эшлисең инде, Аллаһы Тәгаләнең көченә каршы торырлык чара юк шул...

Бәяләр

✓Әлеге вакытта республикада печәннең уртача һәм зур түге: 2000–3000 сум.
✓Ашлык бәяләре: 8,5–10 сум

һава торышы

Алдагы көннәрдә Татарстанның көнчыгыш районнарында 33 градуска кадәр җылытачак. Җомга төнлә 12–17 градус җылы булачак. 1 һәм 2 июльдә республикада кыска вакытлы яшенле яңгыр, көчле җил көтелә. Шимбәгә каршы төнлә һава температурасы 13–18 градуска кадәр төшәчәк. 2 июльдә 11–16 градус булачак. Көндез 22–27 градус җылы булыр, дип өметләндерә синоптиклар. Республиканың Гидрометеоүзәге хәбәр итүенчә, киләсе атна башында да яңгырлар булуы ихтимал. Көндез һава температурасы 25–30 градуска кадәр күтәреләчәк.

КАЙТМАСКА ДИП КИТМӘ

ЯЛ ИТҮ ФАҖИГАГӘ ӘВЕРЕЛМӘСЕН ӨЧЕН, НИНДИ КИҢӘШЛӘРНЕ ИСТӘ ТОТАРГА?

pinterest.com

Ел саен 450ләп мәет! Россия туроператорлары ассоциациясе (АТОР) мәгълүматларына ышансаң, һәр ел төрле илләрдә Россиядән шулкадәр турист үлеп кала. Кызганыч, ялга дип киткәннәрнең туган җирләренә исән-сау кайта алмаулары – хәзер еш очрый торган хәл. Гомумән, үлем-китемнән тыш, ял яменә борчу өстәгән вакыйгалар тагын да күбрәк. Күп очракта ял итүче моңа үзе дә сәбәпче. Әлбәттә, язмыш шуклыгы да бар...

Ике яклы җаваплылык

«Бер барып кайтуымнан соң, бу ил мине үзенә гашыйк итте», – ди хәзерге вакытта Таиландта яшәүче Николай Пермяков. Баксаң, 2018 елда дус-ишләре белән шушы илгә бара, рәхәтләнеп ял итә, табигатькә хозурлана һәм... агулана!

– Кунакханә ризыгын ашап туйгач, кайтыр көннәр җиткәч, Таиланд урамнарындагы төрле аш-суларны авыз итеп карарга булдык. Анда кечкенә генә лареклар шактый. Хәзер нәрсә ашаганымны да хәтерләмим инде. Әмма яхшы гына агуландым, – дип искә алды ул. – Сәяхәтебез «страховка»лы иде. Хастаханә чыгымнарын иминият компаниясе каплады. Тик шунысы бар: компаниядән хастаханәгә рәсми хат килгәнче, миннән залог калдырып торырга сорадылар. Безнең акча белән якынча 10 мең сум тирәсе иде ул чакта.

Николай, хәзер инде бөтенләйгә дип, Таиландка күченеп китте. Хәтта шунда гаилә дә корды. «Хәзер инде кайда нәрсә ашарга икәнен беләм, организмым ияләште. Таиландка килгән дус-ишләремне дә тикшерелгән, белгән урыннарда гына йөртәм», – дип шаярта ул.

Мисырда – акула, экзотик илләрдә – агулану куркынычы, Дагыстанда – текә таулар... Ялның тәме кайда «татлырак» соң? Иминлеккә өстенлек итсәк, кайсы җирләргә игътибар бирергә?

– Куркынычсызлык һәм иминлек – ялның барыбыз да теләгән мөһим өлеше. Бу яктан Берләшкән Гарәп Әмирлекләре аерылып тора. Шулай ук Россиядәге курортлар куркынычсыз булып санала. Шулай да сәяси вазгыятькә бәйле мәсьәләләрне истә тоту зарур, – ди турагент Энҗе Зиннурова. – Комлыкларга килгәндә, Төркия пляжлары иң чиста комлыклардан санала. Әлеге ил дөньяда зәңгәр әләмле – ягъни коенырга иң кулай, сәламәтлек ягыннан уңай дип саналган пляжлар саны буенча өченче урынны алып тора.

Энҗе әйтүенчә, имин дип саналган җирдә дә ул-бу килеп чыгарга мөмкин: «Мисал өчен, Дубайда – сәнәгать җитештерүләре нәтиҗәсендә бүленеп чыккан зарарлы матдәләр белән һаваны артык пычрату (смог), Төркиядә җир тетрәү, урманнар яну очраклары булды. Табигый бәла-казаларны алдан белеп булмый. Моны аңларга, ләкин куертып, үзеңне паникага җиткермәскә кирәк. Куркынычсызлык кагыйдәләрен кеше үзе дә онытмаска тиеш».

Энҗе Зиннурова әйтүенчә, ялга җыенган кеше түбәндәге киңәшләрне исәпкә алырга тиеш:

– Беренче чиратта, ял итү төрен үзеңнең сәламәтлек үзенчәлекләрен күз уңында тотып сайларга һәм аптечка тутырганда гомуми дарулардан кала, өстәмә даруларны да алырга онытмаска. Тур белән ял итәргә барганда, бәла-казалардан иминиятләштерү тур бәясенә кергән була. Бу инде психологик яктан тынычландыра. Гомумән, ял төрен сайлаганда нинди экстремаль очраклар булырга мөмкинлеген һәрвакыт аңлап эш итәргә кирәк. Мәсәлән, таулы җиргә барганда, җайлы, шумый торган аяк киеме кирәк булыу көн кебек ачык. Мальдив утраулары кебек сүүсемнәр, коралл полиплары булган җиргә барганда, аякларны кисмәс өчен, махсус аяк киеме кирәк. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: ялны сайлаганда ук курортның үзенчәлекләрен күз уңында тоту зарур. Мәсәлән, эссе җәйне авыр кичерә торган кешегә җәен Дубай турында уйлау дөрес булмас, чөнки анда бик эссе.

Турагент сүзләренчә, ялда җаваплылык ике яклы була. Ягъни үзеңне кайгыртмасаң, сине кем кайгыртыр соң? Шуңа күрә гомуми киңәшләргә дә колак салырга кирәк, ди әңгәмәдәш.

– Ял иткәндә, баш киеменнән йөрергә тырышыгыз. Аеруча экскурсияләргә йөргәндә моны онытмаска иде. Диңгездә йөзгәндә, яр кырыеннан читкә китмәскә, махсус сызыкны узмаска киңәш ителә. Ни кызганыч, шул чикне узып коенырга яратучылар аз түгел. Суга кергәнче, яр буендагы коткаручы бригадасындагы флагның төсенә игътибар итү зарур. Ул кызыл яки кара төстә булса, суга керергә ярамый – бу ярга акулалар якынлашканда яисә шторм ихтималын аңлатып эленә. Дулкыннар көчле булганда, яр буенда гына йөрергә яки иң сай җирендә йөзәргә киңәш ителә. Дулкын кешене эчкә алып кереп китәргә мөмкин. Шулай ук тәндә яралар булганда, су коенганда аерым игътибар таләп ителә. Суда яшәүчеләр кан тәмен сизә, – дип кисәтте Энҗе.

Булмас, димә

➤Төрле чыганаклардагы мәгълүматларга ышансаң, туристлар еш үлә торган илләргә Төркия, Таиланд, Россия, таулы төбәкләр керә. Сәяхәт өчен имин илләр исемлегендә Австралия, Швеция, Яңа Зеландия, Франция, Нидерланд, Исландия, Ирландия, Греция һәм Япония бар.

➤Үлемгә китергән сәбәпләр: кыргый хайваннар, су хайваннары (медуза, акула) һөҗүме, туристлар төялгән автобусның авариягә эләгүе, суга батып үлү, кыядан төшеп китү, исерткеч эчемлекләрне артык куллану, климат алмашу сәбәпле кискенләшкән хроник чирләр, башка төрле авырулар, таныш түгел ризык белән агулану, пляждагы аттракционнарда куркынычсызлык таләпләрен санга сукмау.

➤Бөтендөнья туристлык оешмасы (UNWTO) мәгълүматлары буенча, ел саен дөньяда туристлар саны 1,3 миллиард кешене тәшкил итә. Һәр 10 меңенче сәяхәтчегә уртача бер үлем очрагы туры килә.

КАЙДА ЯЛ ИТӘРГӘ?

Хәзерге вазгыятьтә, иминлек һәм куркынычсызлык ягыннан караганда, ял итү өчен нинди илләрне сайларга?

Төркия	Австралия
Мисыр	Көньяк-Көнчыгыш Азия илләре
Иран	Черногория
Көнбатыш Африканың мөселман илләре	Испания
Бразилия	Россия төбәкләре
Мексика	элек СССР составында булган илләр
Яңа Зеландия	

**политологлар һәм туроператорлар мәгълүматлары буенча*

Хокук белгече сүзе

Чит илдә ял иткәндә, үзеңне ничек сакларга? «ВТ» юристы Булат Закиров ялдагы кешенең хокукларын искә төшерде.

– Чит илләрдә ял итү еш кына туристик оператор аша оештырыла. Туроператор аша ял оештыру яхшы, чөнки алар күп эшне үз өстенә ала, ял итүчегә акчасын гына түлисе кала. Ләкин уяулыкны югалтырга ашыкмагыз: оператор белән сезнең өчен мөһим булган барлык сорауларны уртага салып сөйләшегез, килешүгә кул куюалдыннан аны игътибар белән укыгыз. Сөйләшкәннәр кәгазьдә дә булсын, – ди белгеч.

Туристик оператор белән оештырылган ял көтелгәнчә килеп чыкмаса, нишләргә?

– Әгәр дә сез ялыгыз туроператор гаебе белән бозылган дип санийсыз икән, «Кулланучы хокукларын яклау турында» һәм «Россиядә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» законнар эшли. Үз хокукларыгызны дәгъва һәм суд аша да якларга мөмкин, – дип кисәтә Булат Закиров.

Чит илгә барыр алдыннан җирле гореф-гадәт, менталитет һәм төп хокукый нормалар белән танышу да файдалы булыр дигән фикердә юрист. Әйтик, тәмәке тарту яки спиртлы эчемлекләр эчү дә зур штрафларга һәм тәртип сакчылары белән мәшәкатьләргә китерергә мөмкин бит. Ялның яме шуннан да китә.

Булат Закиров туристның ял урынында үлеп калу очракларына аерым тукталды. Мондый күңелсез вакыйга була калса, мәетне кире туган җиренә кайтару мәсьәләсе ничек хәл ителә соң?

«Страховка» бар, сәяхәтне туроператор оештырган. *Бу очракта туроператор үзе иминият компаниясе белән хезмәттәшлек итәчәк һәм барысын да оештырачак.*

«Страховка» бар, сәяхәт мөстәкыйль оештырылган. *Бу очракта иминият компаниясе белән туганнар хезмәттәшлек итәчәк һәм кирәкле документлар җыю эше аларга йөкләнәчәк.*

«Страховка» юк. *Җирле хакимиятләр белән хезмәттәшлек, үлгән туристны кире кайтару эше туганнарга калачак. Бу очракта транспортировка бәясе тагын да зуррак булачак, «страховка» бәясеннән артып та китәчәк.*

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

БИРГӘННЕҢ БИТЕНӘ КАРА

ДӘҮЛӘТ ФАТИР АРЕНДАЛАУ ЧЫГЫМНАРЫН КАПЛАРГА БУЛЫШАЧАК

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яшьләргә торак сатып алу җиңеләячәк. Якын арада ук илдә яңа дәүләт программасы гамәлгә керәчәк дип фаразлана. Аның нигезендә 35 яшькә кадәрге яшьләргә фатирны арендага алуга киткән чыгымнарның яртысын каплап бармакчылар. Тик бер шарт белән: дәүләт программасында катнашучылар фатир сатып алу өчен беренчел кертемгә акча тупларга тиеш. Яңалык берьюлы ничә куянның койрыгын тотарга ярдәм итәчәк? Бу сораугa «ВТ» хәбәрчесе ачыклык кертергә тырышты.

Кыйммәтле түбә

Алисә һәм Данис Харисовлар Казанга Чаллыдан күченеп килгән. Алар икесе дә – студент. Укудан бушаган арада эшлиләр.

– Без Чаллыда яшәгәндә үк таныш идек. Икебез дә Казан вузларына укырга кердек. Былтыр өйләнештек. Хәзер башкалада торакны арендага алып торабыз. Әмәт метросы янәшәсендәге яңа йортта урнашкан бер бүлмәле студиядә яшәү аена 22 мең сум тора. Моңа өстәп, ай саен 3–4 мең сум акча коммуналь түләүләргә китә. Мин – булачак хореограф. Укудан бушаган арада бию дәресләре укытам. Данис компьютер программаларын су урынына эчә. Укуы да, эше дә шуңа бәйле. Чыгымнар шактый. Яңа программа безнең кебек яшь гаиләләргә файдалы булыр иде, – ди Алисә.

Быел гыйнварда узган очрашуларның берсендә Россия Президенты Владимир Путин яшьләргә ярдәм чараларын арттырырга кушты. Илнең Төзелеш министрлыгы тәкъдим иткән яңалык әнә шул боерык кысасында башкарылачак дип көтелә. Шуңа күрә аның чынга ашачагына да шик юк.

Шулай итеп, 35 яшькә кадәрге яшьләргә фатирны арендага алып торуга киткән чыгымнарның яртысын кире кайтара башламакчылар. Тик бер шарт белән: дәүләт программасында катнашучылар ташламалы торакта яшәгән арада яңа төзелүче йорттан түбә сатып алу өчен беренчел кертемгә акча тупларга тиеш. Әлеге программада елына 300 меңгә якын кеше катнашачак дип көтелә. Ул быел ук гамәлгә керергә мөмкин.

– Дәүләт яшьләргә ипотека рәсмиләштерү өчен беренчел кертемгә акча тупларга ярдәм итәчәк, – дип аңлаткан Россия төзелеш министры урынбасары Никита Стасишин. – Аренда торагын субсидияләү вакыты чикле. Ул яшьләр тиешле сумманы туплап бетергәнче дәвам итәчәк.

Урынбасар әйтүенчә, әлеге программа, иң беренче чиратта, вуз тәмамлап эшли башлаган, гаилә корырга телегән 23–27 яшьлек егет-кызларга кагылачак. Аның нечкәлекләрен халыкка якын арада ук җиткерергә сүз биргәннәр.

Ун ел көтәсе

Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хәсәенов исә төпләнрәк фикер йөртергә киңәш итә.

– Ил күләмендә гамәлгә кергән ташламалы ипотека соңгы ике – ике ел ярым вакыт эчендә зур шәһәрләрдә һәм, бигрәк тә, беренчел торак базарында бәяләр бик нык үсүенә китерде. Бүген әлеге программа эшләми. Чөнки халыкның, аерым алганда, яшьләрнең фатир сатып алырга акчасы юк. Ә үз торагы булмагач, кеше аны арендага ала, әлбәттә. Моны югарыдагылар да яхшы аңлый. Шуңа күрә илдә торакны арендага алуны юлга-көйгә салып җибәрмәкчеләр. Тик шунысын аңларга кирәк: ташламалы ипотека фатир бәяләре кискен кыйммәтләнүгә китергән кебек үк, яңа программа да аренда бәяләре артуга сәбәп булачак, – ди белгеч. – Бүген зур шәһәрләрдә ипотека буенча айлык түләү шундый ук торакны арендага алып тору бәясеннән ике – ике ярым тапкыр кыйммәтрәк. Ә яңа программа гамәлгә кергәч, чит кеше фатирында яшәү дә кесәгә суга башлаячак. Шул рәвешле, халыкны ничарадан бичара дигәндәй, ипотека рәсмиләштерүгә этәрмәкчеләр. Төзелеш министрлыгы беренчел торак базарын саклап калырга тырыша. Чөнки бүген ташламалы ипотека аркасында, бу өлкәдә вазгыять бик нык кискенләште. Якын арада сату-алулар саны артмаса, милек базарында, бигрәк тә беренчел торак базарында кризис башланырга да мөмкин. Халыкның реаль керем дәрәҗәсе артмаган шартларда кырылып фатир сатып алачаклар дип уйларга җирлек юк. Шуңа күрә әлеге программа нәтиҗәле булмаячак дип саныйм.

«РИА Новости» агентлыгы әле яңа гына үткәргән тикшерү нәтиҗәләренә караганда, Татарстанда яшәүче бер балалы гаиләгә икенчел торак базарыннан 60 квадрат метрлы фатир сатып алу өчен сигез елдан артык акча җыярга кирәк. Ашамыйча, эчмичә бу. Чагыштыру өчен: узган ел башында әлеге күрсәткеч алты ел ярым тәшкил иткән. Ә яңа төзелгән йорттагы фатирны ун елдан артык көтәсе.

Төзеп кенә эш бетми

– Яңа программаның төп асылы торакны арендага бирүчеләрне күләгәдән чыгарудан гыйбарәт, – ди риэлтор Наилә Садриева. – Бүген Казанда бер бүлмәле фатирны арендага бирү уртача 22–23 мең сум тора. Быел гына да әлеге төр торак бәясе 20 процентка кыйммәтләнде. Фатир сорап мөрәҗәгать итүчеләргә бер-ике көн эчендә ошаган торакны табып бирәбез. Әйтергә кирәк, фатирны арендага бирүчеләрнең бик сирәк өлеше генә керемгә салым түли. Без фатир хуҗасы белән торакны арендага алучы арасында килешү төзибез, әлбәттә. Тик бу күбрәк милек хуҗасының хокукларын яклау өчен кирәк. Ә торакны программада катнашучыларга арендага биргән очракта, керемгә салымнан качып котылып булмаячак.

Башкаладагы милек агентлыгы хезмәткәре Мария Пелевина әйтүенчә, Татарстанда яңа төзелүче фатирларның 60 проценты чамасы сатылмаган.

– Ел башыннан бирле беренчел торак базарында сорау 20 процентка кимеде. Бүген Казанда бер бүлмәле фатир уртача 7,9 миллион сум тора. Без беренчел торак базарында бәяләрнең кыйммәт булуы ягыннан Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Сочи шәһәрләреннән генә калышабыз. Бәяләр артса, яңа төзелгән торакның мәйданы кими. Илкүләм саннарга караганда, соңгы ун елда яңа төзелгән фатирларның уртача мәйданы 10 квадрат метрга кимегән. Хәзер ул 52 квадрат метр тәшкил итә. Мондый шартларда ничек тә беренчел торак базарына ярдәм итәргә теләүләре аңлашыла, – ди белгеч.

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, быелның 1 июненнән ипотека буенча беренчел кертемнең минималь күләме дә 20 процентка кадәр артты. Тик бу да чик түгел. Киләсе елның 1 гыйнварыннан ул 30 процентка кадәр җитәчәк дип фаразлана. Быелның гыйнвар – март айларында Татарстанда яшәүчеләр, икенчел торак базары һәм шәхси йортларны да кертеп, 12 меңгә якын ипотека кредиты рәсмиләштергән. Халыкның банкларга ипотека буенча 442 миллиард сум бурычы бар.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Фикер

Алексей ЗУБЕЦ, Социаль-икътисадый тикшеренүләр институты директоры:

– Матди мөмкинлектән чыгып караганда, бүген илдә яшәүчеләр арасында ипотека рәсмиләштерә алучылар саны бетеп бара диярлек. Бәяләр халыкның реаль керем дәрәҗәсенә караганда тизрәк үсә. Бүген илдә яшәүчеләрнең нибары биш процентының гына беренчел ипотекасыз фатир сатып алырлык хәле бар. Ә ипотека йөген тартып бара алучылар саны ун процент чамасы тәшкил итә.

ХАЛЫК АВАЗЫ

7 июльдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Эльвира ВӘЛИЕВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

Акчаны кайтарып буламы?

Май ахырында танылган спорт товарлары кибетеннән аяк киеме алган идек. Тик бер ай үтмәде, аяк киеменең асты тишелеп чыкты. Ул вакытта, ышанычлы марка булганлыктан, чек кирәкме дигәч, юк, дип кенә киткән идек. Чек булмаса, гарантия дә юк дип саналамы? Бу очракта нишләргә мөмкин?

Исемем редакция өчен генә

Марсель Шаһидуллин, Татарстан дәүләт алкоголь инспекциясенең Казан территориаль органы эчке базарын үстерү һәм координацияләү бүлеге җитәкчесе:

– Товарга чек булмау сатып алучының таләпләрен үтәмәү өчен сәбәп була алмый. Ләкин без сатып алучыларга чек яки товарны сатып алганлыкны дәлилләүче документны һәрвакыт алырга киңәш итәбез. Ләкин чек берәүгә дә авыр түгел, ә бәхәсле очракта ул ярдәмгә килә. Бу очракта сатып алучы акчаны кире кайтару яки товарны төзәтеп бирү өчен сатучыга язмача мөрәҗәгать итә ала. Моны сатып алучы ике ел эчендә эшли ала. Әгәр гарантия вакыты куелган һәм ул узган икән, яки бөтенләй билгеләнмәгән булса, сатып алучы товарның сыйфатсыз булуын дәлилләргә тиеш. Әйтик, экспертиза үткәрергә кирәк булуы мөмкин. Чек булмау әле гарантия юк дигән сүз түгел.

Компенсация тиешме?

Без 1993 елда балаларга максатчан кертем ачтык. Хәзерге вакытта безнең исәп-хисап счетында 110 мең сум акчабыз бар. Аның өчен компенсация ала алламы?

Гөлсинә ГЫЙМАЕВА. Зәй районы

Руслан Әхәтов, Сбербанкның «Банк Татарстан» бүлеге идарәчесе урынбасары:

– Сбербанк Россия гражданнарының 1991 елның 20 июненә кадәр ачылган кертемнәрен компенсацияли. Әлеге акча Россия федераль бюджетыннан бүлеп бирелә. Компенсацияне түбәндәге кешеләр ала ала: 1954 елга кадәр туучылар – 1991 елның 20 июненә кертемнәрнең калган өлешеннән өч тапкыр артык күләмдә; 1946–1991 елгылар – 1991 елның 20 июненә кертемнәрнең калган өлешеннән ике тапкыр артык күләмдә. Өч (ике) тапкыр компенсация күләме элегрәк алынган компенсация суммасына һәм кертемнәр буенча өстәмә компенсациягә кими. Компенсация күләме кертемнәрне саклау вакытына бәйле һәм коэффициентлар кулланып билгеләнә. Аның төгәл күләмен сайттагы программа аша да исәпләп чыгарырга мөмкин. Димәк, газета укучының сорауына җавап: 1991 елның 20 июненнән соң ачылган кертемнәргә компенсация каралмаган.

Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде

Укучы фикере

«ЧЕБЕШЛӘРНЕ КҮМГӘЧ САНЫЙЛАР» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Мин Арчадан. Без дә шул партиядән 18 май көнне 25 чеби алган идек. Бүгенгә, ягъни 17 июньгә шуларның 15е үлде. Калганнары терелеп бетә алмыйлар. Сатып алган көрпә, катнаш ризыкларга 4500 сум акча тотылды. Әле моннан тыш үзебездә булган бәрәңгә, бодай, арпа тотылды, күпме хезмәт, нихәтле нервы түгелде. Миңа бу чыгымнарны кем каплар? Пенсионерлар өчен бик күп акча бит бу. 25 чебигә чама белән 15000 мең сум акча тотылды. Бу – безнең бер айлык пенсия. Кеше көлкесе бит.

ТАҺИР

3 июль | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
07.05, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00 Специальный выпуск программы «Здравствуйте!» Гость программы – Р.Б. Габитов 16+
09.20, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». Телесериал 16+
10.00, 23.30 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.40 «СЕБЕР КИЯВЕ». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Ком сәгате» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Гаилә учагы» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.20 «Соотечественники». Фешин. Монолог художника 16+
00.45 «Каравай» 6+
01.10 «Таяну ноктасы» 16+
01.35 «КВН РТ – 2022» 16+
02.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.45 «Йөрәктән – йөрәккә». РСФСРның халык артисты Айрат Арсланов турында телеочерк 16+
07.00, 11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
07.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». Телевизион нәфис фильм 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 Г.Кариев. «АРТИСТ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Флера Сафиуллина турында телеочерк 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 Г.Камал. «БЕРЕНЧЕ ТЕАТР». Телеспектакль 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.15, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30, 00.40 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
01.05 Юлчы. «АЕРЫЛАБЫЗ, АХРЫСЫ». Әлмәт татар дәүләт драма театры спектакле 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Милош Бикович в многосерийном фильме «МАГОМАЕВ» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Мария Андреева, Евгений Цыганов, Надежда Маркина, Пётр Зайченко, Борис Невзоров. «СОФИЯ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ВСЁ КАК У ЛЮДЕЙ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 16+
23.25 «Вечер» 12+
02.05 «РАЯ ЗНАЕТ ВСЁ!» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.20 «Спортивный интерес» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 18.25, 22.30 Новости
07.05, 20.30, 22.35 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «Кубок PARI Премьер». Специальный репортаж 12+
10.25, 01.10 «Спортивный век» 12+
11.25 Karate Combat 2023. Трансляция из США 16+
12.35, 05.15 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.55 «География спорта. Москва» 12+
15.25 «В ПОГОНЕ ЗА ВЕТРОМ» 12+
17.25 «Громко». Прямой эфир
18.30 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 4. Прямая трансляция из Москвы
21.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
23.20 Бокс. Bare Knuckle FC. Рико Франко против Калеба Харриса. Трансляция из Великобритании 16+
00.10 «Вы это видели» 12+
02.10 «Территория спорта» 12+
02.40 Новости 0+
02.45 Пляжный футбол. OLIMPBET Чемпионат России. «Кристалл» (Санкт-Петербург) – «Локомотив» (Москва) 0+
04.00 Пляжный футбол. OLIMPBET Чемпионат России. «Краснодар-ЮМР» – «Саратов» 0+

НТВ

05.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Гоша Куценко, Екатерина Волкова. «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00 Премьера. «ПАЗЛ» (S) 16+
22.10, 00.00 «МЕДИАТОР» (S) 16+
00.30 «Основано на реальных событиях» 16+
01.35 Сериал «ГОНЧИЕ» (S) 16+
04.45 «Военно-исторические маршруты» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.30 «Давай разведёмся!» 16+
09.35 «Тест на отцовство» 16+
11.45 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Охота на хищницу» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.00 «Верну любимого» 16+
14.35 «Голоса ушедших душ» 16+
15.10 «ГОРНАЯ БОЛЕЗНЬ» 16+
19.00 «О ЧЁМ ОНА МОЛЧИТ» 16+
23.05 «Понять. Простить» 16+
00.15 «Порча» 16+
00.40 «Знахарка» 16+
01.05 «Верну любимого» 16+
01.35 «Голоса ушедших душ» 16+
02.00 «ЛЮБОВЬ КАК МОТИВ» 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «БУХТА ПРОПАВШИХ ДАЙВЕРОВ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.50 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ». Телесериал. 1-я серия 12+
12.25 «По горячим следам» 16+
12.45, 13.25 «ЕСТЕСТВЕННЫЙ ОТБОР». Телесериал. 1-я – 5-я серии 16+
18.00 «Битва за Россию». Документальный сериал. «Бородинская битва. Александр I против Наполеона» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам». Премьера! 16+
20.10 «Загадки века». Документальный сериал 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «В СТРЕЛЯЮЩЕЙ ГЛУШИ» 12+
01.55 «ТЫ ПОМНИШЬ?» 12+
03.20 «Выбор Филби». Документальный фильм 12+
03.55 «ЕСТЕСТВЕННЫЙ ОТБОР». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

4 июль | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
07.05, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Соотечественники» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Мастер этнохудожественного кадра 6+
00.50 «Соотечественники». Геннадий Прытков. Актером быть просто 16+
01.15 «КВН РТ – 2022» 12+
02.05 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Башваткыч» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.50 «Йөрәктән – йөрәккә». Бату Мулюков турында телеочерк 16+
07.00, 11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
07.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». Телевизион нәфис фильм 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05 «Ком сәгате» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.10, 22.15, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Ком сәгате» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
01.05 М.Гыйләҗев. «БАЛА БАЛАСЫ БАЛДАН ТАТЛЫ». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «МАГОМАЕВ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Мария Андреева, Евгений Цыганов, Надежда Маркина, Пётр Зайченко, Борис Невзоров. «СОФИЯ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ВСЁ КАК У ЛЮДЕЙ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 16+
23.25 «Вечер» 12+
02.05 «РАЯ ЗНАЕТ ВСЁ!» 12+
03.55 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.20 «Спортивный интерес» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 18.10, 22.30 Новости
07.05, 16.10, 21.40 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35, 05.15 Специальный репортаж 12+
10.25, 01.10 «Спортивный век» 12+
11.25 Karate Combat 2023. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.55, 16.25 Пляжный футбол. OLIMPBET Чемпионат России. Женщины. Прямая трансляция
17.40 «Что по спорту? Санкт-Петербург» 12+
18.15 Все на Кубок PARI Премьер! Прямой эфир
19.00 Футбол. Кубок PARI Премьер. «Црвена Звезда» (Сербия) – «Зенит» (Россия). Прямая трансляция из Санкт-Петербурга
22.35 Смешанные единоборства. UFC. Шон Стрикланд против Абусупьяна Магомедова. Трансляция из США 16+
00.10 «Вы это видели» 12+
02.10 «Территория спорта» 12+
02.40 Новости 0+
02.45, 04.00 Пляжный футбол. OLIMPBET Чемпионат России. Женщины 0+
05.35 «Здоровый образ. Регби» 12+

НТВ

04.55 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00 «ПАЗЛ» (S) 16+
22.10, 00.00 «МЕДИАТОР» (S) 16+
00.30 «Основано на реальных событиях» 16+
01.25 Сериал «ГОНЧИЕ» (S) 16+
04.30 «Военно-исторические маршруты» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.20 «Давай разведёмся!» 16+
09.20 «Тест на отцовство» 16+
11.35 «Понять. Простить» 16+
12.50 «Порча». «Медальон» 16+
13.20 «Знахарка» 16+
13.50 «Верну любимого» 16+
14.25 «Голоса ушедших душ» 16+
15.00 «САШИНО ДЕЛО» 16+
19.00 «НЕЛЮБОВЬ» 16+
22.35 «Понять. Простить» 16+
23.40 «Порча» 16+
00.10 «Знахарка» 16+
00.35 «Верну любимого» 16+
01.00 «Голоса ушедших душ» 16+
01.25 «ЛЮБИМАЯ» 16+
02.55 «Тест на отцовство» 16+
04.35 «Давай разведёмся!» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ЕСТЕСТВЕННЫЙ ОТБОР». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.55 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ». Телесериал. 2-я серия 12+
12.30 «По горячим следам» 16+
12.45, 13.25 «ЕСТЕСТВЕННЫЙ ОТБОР». Телесериал. 6-я – 8-я серии 16+
15.55 «РЫСЬ» 16+
18.00 «Битва за Россию». Документальный сериал. «Битва на Березине. Александр I против Наполеона» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого». «Дело об «НЛО». Китайские шары над США» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ТРОЙНАЯ ПРОВЕРКА» 12+
02.10 «ПОЕЗД ВНЕ РАСПИСАНИЯ» 12+
03.25 «Калашников». Документальный фильм 12+
03.55 «ЕСТЕСТВЕННЫЙ ОТБОР». Телесериал. 5-я и 6-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга мөһим өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Әшрәпов** Мөбарәк Әшрәф улы, республиканың финанс системасын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының икътисад бүлеге башлыгы **Буканова** Елена Юрьевна, республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе өчен «Хайперфудс холдинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, «КОМОС ГРУПП» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте идарәчесе – шәхси эшкуары **Шутов** Андрей Васильевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

«КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятенең фәнни-техник үзәге автомобиль агрегатлары баш конструкторы хезмәте трансмиссия конструкторлык бүлегенең әйләндерү көпчәкләрен тоташтыру җайланмалары баш белгече **Логунов** Юрий Михайловичка **«Татарстан Республикасының атказанган уйлап табучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятенең фәнни-техник үзәге гомуми техник кулланылыштагы автомобильләр баш конструкторы хезмәтенең көпчәкле шассилар баш конструкторы – 3 нче махсус конструкторлык бюросы (көпчәк шассилары) башлыгы **Максименко** Сергей Владимировичка **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Казан» халыкара аэропорты» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары – җәмгыятьнең финанс директоры **Галләмова** Эльмира Рәис кызына, «МЕДТЕХНИКА» җитештерү-техник берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры **Ершова** Татьяна Яковлевнага, «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенең финанс-килешүләр идарәсе башлыгы **Козихин** Андрей Николаевичка, «АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) баш бухгалтеры урынбасары – Бухгалтерлык һәм салым исәбе департаментының салым исәбе идарәсе башлыгы **Крылова** Наталья Владимировнага, «Казан шәһәре Киров районының юлларны төзекләндерү-эксплуатацияләү идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе директорының финанслар буенча урынбасары – баш бухгалтер **Насыйбуллина** Айсылу Әсәт кызына, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территорияне үстерү бүлеге баш белгече **Сәлахетдинов** Марат Марс улына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының үзәкләштерелгән бухгалтериясе җитәкчесе урынбасары **Таҗиева** Эльмира Юнис кызына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаменты Казан шәһәре территориаль бүлекчәсенең социаль өлкәне финанслау бүлеге башлыгы **Хөснетдинова** Виктория Борисовнага, «Авиасервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте финанс директоры – баш бухгалтеры **Юнысова** Луиза Рәсим кызына **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең «Түбән Кама электр челтәрләре» филиалы югары вольтлы линияләр хезмәте башлыгы **Булатов** Җәлил Амил улына, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең «Казан электр челтәрләре» филиалы Көньяк район электр челтәрләре бүленеш челтәрләрен эшләтү буенча электромонтеры **Галәүтдинов** Закирҗан Мәгъсүмҗан улына, «Татэнерго» акционер җәмгыятенең «1 номерлы Казан җылылык-электр үзәге» филиалы технологик процессларга идарә итү автоматлаштырылган системалары цехы технологик саклык чаралары һәм технологик сигнализацияләр, электр приводлары һәм автоматларга техник хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү төркеменең электр станцияләре автоматларын һәм үлчәү чараларын төзекләндерүче һәм аларга хезмәт күрсәтүче электрослесаре **Закиров** Тимерхан Бәйрәмхан улына, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятенең фәнни-техник үзәге баш инженеры бүлекчәсенең баш энергетигы **Родионов** Александр Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, әнисе

ВӘЛИЕВА Миңҗиһан Гыйният кызы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Алексеевскдорстрой» ҖЧҖнең Директорлар советы рәисе Вәлиев Фоат Вәли улының авыр кайгысын уртаклаша. Сезнең белән бергә кайгырабыз һәм зур югалту хәсрәтен бүлешәбез.

Спас муниципаль районы Советы, Башкарма комитеты,

ВӘЛИЕВА Миңҗиһан Гыйният кызы

вафат булу сәбәпле, ихластан, Вәлиев Фоат Вәли улының, якыннарының, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша. Зур югалту хәсрәтен бүлешәбез.

Спас районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге Советы,

ВӘЛИЕВА Миңҗиһан Гыйният кызы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Вәлиев Фоат Вәли улының, барлык туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЭШ ЯНЫНА ЯЛ КИРӘК

Күбебез җәйге чорны бакчада уздыра. Ә анда һәркемгә эш җитәрлек. Эшкә алданып, еш кына сәламәтлек тә онытыла. Җәй көнне бакчада эшләгәндә нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк? Авыр эш вакытында бил тотса, үтәли җил бәрсә, ни эшләргә?

Казанның 21 номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Регина ГАЛИУЛЛИНА бу уңайдан киңәшләрен бирде.

✓ Көтеп алган җәй ялы белән генә түгел, бакча эшләре белән дә күңелгә якын. Күпләр, анда чакта бөтен авыруларым онытыла, ди. Әмма бу хакта һич кенә дә истән чыгарырга ярамый. Җәйге чорда бакчада казынганда радикулит, артроз кебек чирләрдән интеккән, инсульт, инфаркт кичергән кешеләргә аеруча сак булырга кирәк. Бу чорда кан басымы күтәрелү, эссе кагу, эч китү очраклары да арта.

✓ Кояш иң нык кыздырган көндезге сәгатьләрдә бакчада эшләмәү хәерле. Моның өчен иртәнге һәм кичке сәгатьләрдән дә яхшысы юк. Төгәлрәк әйтсәк, бакчада иртәнге сәгать унга кадәр һәм кичке сәгать дүрттән соң эшләү хәерле. Эсседә эшләгән очракта да ара-тирә күләгәдә ял иткәләп, чамасын белеп кенә йөрегез. Урамда артык бөркү яки дымлы булган көннәрдә дә бакча эшләрен кичектереп торырга киңәш ителә. Ник дигәндә, андый чакта эссе сугу ихтималы икеләтә арта.

✓ Урамга чыгар алдыннан кояштан саклый торган крем сөртергә онытмагыз. Аның саклау дәрәҗәсе 50дән ким булмасын. Онытмагыз: җәй көне хәтта болытлы көнне дә кояш ашый. Шуңа күрә, көн болытлы, дип тынычлап, кояштан саклаучы крем сөртмичә йөрергә ярамый. Бакчада эшләгәндә бигрәк тә.

✓ Бакчада баш киемсез эшләмәгез. Җәйге челләдә бакчада эшләгәндә киҗемамык тукымадан тегелгән киемнән йөрегез. Синтетик материаллар тирләтә, һава йөртми, нәтиҗәдә хәлне ала.

✓ Көн дәвамында чиста су эчеп торыгыз. Җәйге челләдә кофеинлы, баллы, газлы, исерткеч эчемлекләрдән баш тарту хәерле. Чиста су эчәргә яратмаган кеше лимон телеме салынган салкын кара яки яшел чәй эчә ала. Эсседә сыеклыкны күпме эчсәң дә, куркыныч түгел. Җәен чиста суны пыяла савытта сакларга кирәк. Кояш кыздырганда пластик шешә

vk.com

җылына һәм аның составындагы зарарлы матдәләр суга да күчәргә мөмкин.

✓ Бакчада эшләгәндә хәле авырайган кешене иң элек салкынча урынга күчерергә кирәк. Андый чакта башта кешенең тән температурасын үлчисе. Тәненә салкынча су сиптереп алырга, салкынча компресс куярга мөмкин. Кеше аңын җуйса, көзән җыера башласа, кичекмәстән «ашыгыч ярдәм» чакыртырга кирәк.

✓ Бакчада эшләгәндә бил тотса, арка авыртса, авыртуны баса торган мазь, гель ярдәмгә киләчәк. Энәле паласка (Кузнецов аппликаторы) яту да ярдәм итә. Ул мускуллар киеренкелеген бетереп, авыртуны басачак. Махсус күнегүләр дә ясый аласыз.

✓ Бакча чорында эш белән ялны чиратлаштырырга онытмагыз. 15–20 минут эшләгәч, бераз ял итеп алырга кирәк.

Табигать даруханәсе

Яфрагы шифалырак

Бакча күрке булган кара карлыган җиләгендә B, P, E, A, C, K төркеменә кергән витаминнар, фосфор кислотасы, шикәр, тимер һәм калий тупланган. Яфраклары магний, марганец, көмеш, кургаш, бакыр, эфир майларына бай.

▶ Кара карлыганда C витамины шулкадәр күп, организмны тәүлек буена җитәрлек дәрәҗәдә тукландыру өчен 20 җиләк ашап кую да җитә. Шуңа күрә ул авырганда организмны ныгыта, иммунитетны көчәйтә.

▶ Бу җимеш йөрәк-кан тамырлары чирләрен, яман шеш, Альцгеймер авыруларын кисәтә. Моннан тыш ул бөер һәм бавыр, тын юллары, шикәр авыруларын да булдырмаска ярдәм итә.

▶ Карлыганны изеп әзерләнгән сокны операция кичергән һәм организмы хәлсезләнгән кешеләргә эчәргә киңәш итәләр. Ник дигәндә, ул хәл кертә, тиз арада тернәкләнергә булыша. Карлыганны пешереп эчү югары кан басымын җайга салырга, азканлылыкны, гастритны җиңәргә ярдәм итә.

▶ Көчле ютәл борчыганда, кара карлыганның суын сыгып, аны шикәр һәм бал белән болгатып эчегез. Бераз су өстәлгән карлыган согы белән тамакны чайкату ангинадан котылырга да ярдәм итә.

▶ Карлыганның яфрагы җимешенә караганда да файдалырак. Шуңа күрә аның яфракларын төнәтеп эчәргә кушалар. Болай эшләгәндә ашказаны авыруларын гына җиңеп калмыйча, организмдагы зыянлы матдәләрне юып чыгарырга, матдәләр алмашы бозылса, аны да җайга салырга мөмкин. Төнәтмәне ясар өчен, яңа гына өзелгән яки киптерелгән яфраклар кирәк. Әлбәттә инде, яңа гына өзелгәне әйбәтрәк. Кайнар суны әфлисун, алма яки анар согы белән кушып, шушы катнашманы карлыган яфраклары өстенә салырга кирәк. Соңыннан өстен каплап, шуны берничә көн төнәтергә һәм көнгә яртышар стакан эчәсе булачак. Тире авырулары булган кешеләргә исә, карлыган яфраклары төнәтмәсе кушып, ванна керергә киңәш ителә.

Үзем сынадым

КӘБЕСТӘ КОТКАРДЫ

Озак еллар аяктагы шпорадан интектем. Хәзер аякка курыкмыйча басып йөри алам. Дәвалануның бер авырлыгы да юк. Моның өчен төнгә үкчәгә бал сөртеп, кәбестә яфрагы гына урап куярга кирәк. Бер ай дигәндә шпораның эзе дә калмады.

Зәһрә ГЫЙМАДОВА. Апас

КАНӘФЕР ТЕРЕЛТТЕ

Без салкын тигәндә канәфернең файдасын күрәбез. Андый чакта 10 бөртек канәферне 1 стакан кайнар суда төнәтеп эчәргә кирәк. Борынга томау төшкәндә тамызсаң да зыяны юк.

Әлфия ХИСАМОВА. Питрәч

Абау!

Даими рәвештә йокы туймау артериаль гипертония килеп чыгу ихтималын 1,5 тапкыр арттыра. Сеченов университетының нерв авырулары һәм нейрохирургия кафедрасы доценты Михаил Полуэктов сүзләренә караганда, даими рәвештә йокы туймаудан интеккән кешеләр арасында йөрәк авырулары, шикәр чире дә ешрак очрый. Андый чакта кешенең иммунитеты төшә, организмның инфекцияләргә бирешүчәнлеге арта, ди белгеч.

Исеңдә тот!

Холкың нинди – чирең шундый

Кешенең нинди чирдән интегүе аның характер үзенчәлекләренә дә бәйле, дип ышандыра Норвегия галимнәре. Белгечләр ясаган кызыклы нәтиҗәләрне укучыларыбыз игътибарына да тәкъдим итәбез.

- Даими рәвештә төшенкелеккә бирелүчеләр еш кына ашказаны һәм баш авыртуыннан интегә.
- Агрессив кешеләр гипертониягә бирешә, аларның иммунитеты какшый.
- Оялчан кешеләрдә инсульт булу ихтималы зур, алар йөрәк өянәкләренә һәм төрле инфекцияләргә тиз бирешә.
- Хис-кичерешләрен тышка чыгармаучылар астмадан интегә.
- Аралашучан, хисчән кешеләр күп авырулардан сакланган кешеләр төркеменә керә. Алар проблемалары белән бүлешергә курыкмый һәм бик тиз савыгалар.
- Саран кешенең – башы, куркак кешенең бөере авырта.
- Башларында чамадан тыш мәгълүмат булган кешеләр эч катудан азаплана.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ҖӘЙНЕҢ МАТУРЛЫГЫ – БАКЧАДА

Укучыларны кызыксындырган сорауларга бакчачы-блогер Эльмира ИСХАКОВА җавап бирә.

? Борычларның чәчәкләре ачылмый. Нишләтергә икән?

Сания ХӘБИБУЛЛИНА.
Балык Бистәсе

– Борыч – нәзберек үсемлек. Үсү шартлары килешмәсә, 1 ай да, 2 ай да җимешләнмичә утырырга мөмкин. Шуны онытмагыз: борыч җылы ярата. Ләкин эссене түгел. Теплицада һава температурасы 30 градустан артып китсә, чәчәкләрнең тиз генә ачылуын көтәсе юк. Чәчәк атканда, мондый эсселек бөреләрен коюга китерә. 20 градустан түбән булса да, бөреләр коела.

Ә инде дымлылык кирәгеннән артык икән, серкәләнү туктала. Артык дымнан серкәләр ябыша чөнки. Шуңа күрә атнага бер тапкыр гына, әмма җылы су сибәргә кирәк. Шунысы да бар: беренче чәчәгеннән алган очракта, борыч әйбәтрәк үсә. Үсемлекнең бөтен көчен ала ул. Арада иң эре борыч шул беренчесе, калганнары ваграк була. Аны орлыкка калдырырга теләсәгез генә өзмәгез. Беренче чәчәкне өзеп ташлаган очракта, уңышы әйбәт һәм борычларның барысы да бер чама эрелектә булачак.

? Викториянең җиләк бирмәгән төпләрен калдырыргамы, әллә йолкып алыргамы? Киләсе елга аларны калдыруның мәгънәсе булырмы?

Римма ҖАМАЛИЕВА.
Чирмешән районы

– Гадәттә яшь үсентеләр җиләк бирмичә кала. Ләкин алар киләсе елда бирәчәк. Шуңа күрә мыекларын гына өзегез. Киләчәктә алардан эре-эре җиләкләр җыеп алачаксыз.

? Кыяр яфракларында ак таплар барлыкка килде. Бу нәрсәдән булырга мөмкин икән?

Фәния ЗАРИПОВА.
Биектау районы

– Ончыл чык (мучнистая роса) гадәттә үсентеләрне шулай зарарлый. Бу очракта, әйтик, Алирин Б препаратын куллану әйбәт нәтиҗә бирә. Чир артык азынмаса, аны бер тапкыр кулланy да җитә. Яисә 5 литр суга 1 чәй кашыгы чәй содасы, бераз кер сабынын юнып салып, катнашма ясап сиптерсәң дә була.

vk.com

? Эре помидор үстерү серләрен аңлатып үтмәссезме?

Алсу НИГЪМӘТУЛЛИНА.
Тәтеш районы

– Беренчедән, томатка суны сирәк, әмма күп итеп сибәргә кирәк. Су якынча +24 градус җылылыкта булырга тиеш. Икенчедән, тукландыруга әһәмият бирергә. 10 литр суга 4 тамчы йод тамызып, атнага бер тапкыр шуны сибәргә. Болай эшләгәндә, помидорлар эре булачак, тизрәк тә өлгерәчәк. Сүз уңаеннан, помидорлар төшкәч, көл һәм тоз эремәсе белән тукландырганда, алар тәмлерәк, татлырак булып пешәчәк. Моның өчен 10 литр суга бер аш кашыгы тоз һәм бер стакан көл салып болгатырга. Һәрбер төпкә ярты-шар литр сибәргә.

Белеп тор!

ГОРЧИЦАДАН БӨКЕ ЯСАУ

«Малосольный» кыяр яки ачылган банкадагы яшелчә бозылмасын өчен, горчицалы бөке кулланырга мөмкин.

Моның өчен горчица порошогы, су һәм, марляны 2–3 катлап, ике түгәрәк ясарга кирәк. Порошокны чынаякка салып, берәр аш кашыгы су өсти-өсти, камыр басабыз. Марлядан ясалган бер түгәрәкне капкачның эчке өлешенә урнаштырабыз. Өстенә горчица камырын тигез итеп сылыйбыз. Камырны марлядан ясалган икенче түгәрәк белән каплыйбыз һәм бармаклар белән тыгызлыйбыз. Бөке әзер! Банканы горчицалы капкач белән каплыйбыз. Болай эшләгәндә, яшелчә әчемәячәк һәм күгәрмәячәк.

КАПКАЧЫ АТМАСЫН

Кыяр яки башка яшелчәне кышка тозлап куйганнан соң тозлыгы болгана башласа, банканың тимер капкачына берникадәр тоз сибәргә кирәк. Тозлыгы тоныкланачак (болганчыгы төпкә утырачак) һәм банка капкачы атмаячак.

Тәмле булсын!

Чия бәлеше

Алсу ҖАМАЛОВА рецепты

Кирәк булачак: *500 г бодай оны, 50 г атланмай, 1 стакан сөт (3,2 процентлы), 3 йомырка, 25 г коры чүпрә, 300 г төше алынган чия, 1 стакан шикәр комы, 2 аш кашыгы крахмал, 2 аш кашыгы лимон согы, 1 аш кашыгы коньяк (үзенчәлекле тәм кертә), 40 мл су.*

Онны иләп, яртысына җылы сөт һәм чүпрә салабыз да, камыр изеп, җылы урынга куябыз. Чи йомыркага (сытып) шикәр комы һәм йомшарган атланмай салып болгатабыз. Катнашманы сыек камырга салып, калган он белән басабыз. Камырны 1 сәгатькә җылы урынга куябыз. Юып, төшләреннән арындырылган чиягә су һәм шикәр комы салып, 10 минут кайнатабыз. Суынгач, крахмал, лимон согы һәм коньяк өстибез.

Камырның өчтән ике өлешеннән җәймә ясап, майлы табага салабыз. Эчлекне шуңа тигез итеп урнаштырабыз. Калган камырны җәеп, тасмалап (киңрәк итеп) кисәбез һәм шулар белән бәлешне каплыйбыз. Кырыйларын бөгәбез. Өстен йомырка сарысы белән майлап, 180 градуслы мичтә 30 минут пешерәбез.

Кирәге чыгар

КӘБЕСТӘ ЯФРАГЫН ЙОМШАРТУ

☑ Голубцы ясаганда, кәбестә яфраклары сынмасын-ертылмасын өчен, кочанне берникадәр вакытка туңдыргычка куеп торырга кирәк.

☑ Ризык әзерләргә 10–12 сәгать кала, туңдыргычтан алып, зуррак савытка куеп эретергә.

☑ Эрегәч, кәбестә яфракларын кисеп алырга гына кала. Алар голубцы ясау өчен тулысынча әзер!

Беләсеңме?

Матрас чистарту серләре

Тышлыгын юу. Иң элек матрасның тышлыгын салдырып, машинага салабыз да югары температурада юып алабыз. Тышлыгы юк икән, аны булдыру ягын карарга кирәк. Ник дигәндә, матрасны пычранудан гына түгел, бөлки, тузан талпаны, гөмбәчек, бактерияләрнең урынҗиргә эләгүеннән дә саклый ул.

Чүптән һәм истән арындыру. Матраска күп итеп чәй содасы сибәбез һәм 5–7 минут тотабыз. Шуннан соң соданы тузан суырткыч белән суыртып алабыз. Шул рәвешле матрастагы тузан, чүп, чәч бөртекләре генә түгел, сөрсегән исләр дә юкка чыгачак.

Тапларны бетерү. Май, ялгыш түгелгән сыеклык тапларына чәй содасы, савыт-саба юу сыекчасы һәм водород перекиссеннән катнашма ясап сылыйбыз. Катнашма кипкәч, чүпрәк белән сөртеп, тузан суырткыч белән чистартып алабыз.

«Кыздыру» яки җилләтү. Авыл җирендә яки шәһәрдә үз йорты белән яшәүчеләргә, матрасны урамга алып чыгып, берничә сәгать кояшта «кыздыру»ның бернинди авырлыгы юк. Саф һава һәм кояшның ультрашәмәхә нурлары микробларны, күгәрек, вак паразит бөҗәкләрне юкка чыгара.

Мондый мөмкинлеккә ия булмаучылар исә болай эшли: матрасны серкәле суда (1 литр суга 2–3 аш кашыгы серкә) чылатып, әйбәтләп сыгылган иске җәймә белән каплый да, өстен тузан каккыч белән кагып, ачык тәрәзә янында 2–4 сәгатькә калдыра.

Укучы киңәше

КУЛГА ТӘРБИЯ КИРӘК

Бакчада эшләмичә калган көнем юк диярлек. Шуңа да карамастан, култырнакларым һәрвакыт тәртиптә. Аларны тәрбияләү серләрен бәлем чөнки. Помидор сабакларыннан каракучкыл төскә кергән кулларны аш серкәсе яки лимон кислотасы эремәсе (суга берәз гына тамызырга) белән, яисә рәваҗ кисәге белән ышкып чистартам.

Чүп утаганда, хәтта пирчәткә аша да тузан-пычрак кереп, тырнаклар йомшара, сынучанга әйләнә. Аларны ныгыту өчен атнасына 2–3 тапкыр «ванна» ясыйм. 1 стакан кайнар суга 1 чәй кашыгы каһвә төбе (мин бөртекле каһвә генә кулланам) салып, эремә ясыйм. 10–15 минут дәвамында кулларымны эремәгә тыгып утырам. Шуннан соң корытып сөртәм дә крем сылыйм.

Әлфия НӘҖИПОВА.
Чаллы

БӨТЕН ӨМЕТ – ХОДАЙДА

Адәм баласының бөтен гомере сорауларга җавап эзләп уза. Яңа көн яңа вакыйгалар, яңа мәшәкатьләр алып килеп кенә тора. Бүгенге сәхифәбездә укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга җавап эзләрбез.

Сорауларга Лаеш районындагы «Ихлас» мәчете имамы Мөдәррис ГЫЙМРАНОВ җавап бирде.

? Әбиемнең өен сүттек. Аннан бик күп иске дини календарьлар чыкты. Аларны ни эшләтергә икән?

– Бу календарьларны куяр, саклар урын булмаса, аларны яндыру хәерле. Анда Аллаһ сүзләре, хәдисләр булырга мөмкин. Аларга ихтирамсызлык булмасын, алар ниндидер хәерсез урыннарга барып эләкмәсен өчен эшләнә бу. Дини календарь, китаплар теләсә кайда аунап ятарга тиеш түгел.

? Балага мәрхүм туганыңның исемен кушсаң ярыймы? Ул аның язмышын кабатламасмы?

– Дөньяда һәрчак кемдер кемнеңдер исемен кабатлый. Шәхсән миңа да әтинең 18 яшендә комбайнда эшләгәндә ток чыбыгына эләгеп вафат булган абыйсының исемен кушканнар. Әлхәмделилләһ, аның язмышын кабатламадым. Динебездә андый нәрсә юк. Иманның алты баганасы бар. Шуларның берсе – тәкъдирнең яхшысы да, начары да Аллаһы Тәгаләдән икәненә инанау. Рәсүлебез бер хәдисендә: «Бел: сиңа киләсе булмаган әйбер сиңа килмәс, сиңа киләсе әйбер сине әйләнеп узмас», – ди. Шуңа күрә тәкъдирдән узып булмый. Нинди генә исем кушылса да, баланың язмышы туганда ук язылган була. Беркем дә беркем язмышы белән яшәми. Шуңа күрә балага мәрхүм кеше исемен кушуның бер зыяны да юк.

? Затлы савыт-саба сатып алган идем. Шуның бер тәлинкәсе кителде. Зыянлы түгел, кулланып була үзе. Мөселманга мондый китек савыт-сабадан ашарга ярыймы икән?

– Рәсүлебез Мөхәммәд сәлләллаһү галәйһи вә сәлләм алтын һәм көмеш савыт-саба куллануны тыйган. «Бу – кәферләрнең савыт-сабасы, ә сезнең юл җәннәттә булыр», – дигән ул. Алтын-көмеш бер үк вакытта исәп-хисап материалы да булып тора бит әле. Бу сүз кешедә тәкәбберлек уянмасын, дөньядагы ләззәткә бирелмәсен өчен дә әйтелгән. Тагын бер хәдистән аңлашылганча, мөселманга чатнаган савыт-саба куллану, андагы ризыкка өрү дә киңәш ителми. Болай эшләсәң, гөнаһ була, дигән сүз түгел бу. Эшләмәү хәерле булган, мәкрүһ гамәл санала.

? Сул кул белән ризык ашамаска кушалар. Исламда бу турыда ни диелә?

– Рәсүлебез: «Әгәр сезнең берәрегез ашаса, уң кул белән ашасын, уң кул белән эчсен. Дөреслектә, шайтан сул кул белән ашый һәм сул кул белән эчә», – дигән. Бер кеше сул кул белән ашап утырган вакытта Рәсүлебез аңа: «Уң кулың белән аша», – ди. Ул кеше исә: «Мин ашый алмыйм», – дип җавап кайтара һәм ул кешенең уң як гәүдәсе параличлана. Аллаһы Тәгалә аңа шундый газап бирә. Шуңа күрә динебез кануннары буенча уң кул белән ашау-эчү генә рөхсәт ителә. Кызганыч, моны еш кына диндә булган мөселманнар да үтәми.

? Якын туганыма күптәннән үпкә саклыйм. Ничек кенә тырышсам да, аны кичерә алмыйм. Догалар ярдәмендә берәр ничек күңел тынычлыгы табып буламы икән?

– Үз белдегең белән капкын куярга ярамый. Бу бит инде, икенче төрле әйткәндә, кыргый хайванны аулау дигән сүз. Ау сезонының билгеләнгән вакыты бар. Җитмәсә, аның өчен рәсми төстә рөхсәт алу да кирәк. Теләсә кайсы вакытта рөхсәтсез тоту яки үтерү браконьерлыкка керә. Штраф салырга да мөмкиннәр.

:: Кешеләр бу бәладән ничек саклана ала соң?

– Әгәр ишегалдында эт яки мәче яшәсә, ләтчә, сасы көзән кебек җәнлекләр тавык сарае янына якын да килми. Төнгелеккә тавыкларны яхшылап ябарга, бернинди тишек тә, ярык та калдырмаска кирәк. Мал чалганнан соң калдыкларны хуҗалык корылмалары янында калдырмасалар иде. Бу кыргый хайваннарны бигрәк тә җәлеп итә. Тавыкларга тәгаенләнгән сарайны гел карап, ныгытып торырга кирәк. Черек такталар кыргый хайваннар өчен каршылык түгел. Кайчагында чебешләр өчен ясалган читлеккә бер метр озынлыктагы «аяк» ясап куялар. Янәсе, анда сикереп менә алмый. Бу да саклану чарасы түгел, кыргый хайван өстән дә сикереп төшә ала.

:: Без сүз башында ташландык өйләр турында сүз кузгаткан идек. Бәлки, төлкеләрнең авылда «төпләнүе» шуңа дә бәйледер?

– Монысы турында авыл җирлекләре кайгыртырга тиеш дип беләм. Ташландык йортларның хуҗалары табылып, тирә-юне чистартылса, чүп уләннән арындырылса, ишеккә, каралты-кураларга йозак эленсә, кыргый хайваннар бу дәрәҗәдә ияләшмәс иде. Аннан килеп, шунысын да әйтергә кирәк: без закон буенча авыл эчендә хайваннарны юк итү белән шөгыльләнә алмыйбыз. Бу торак урыннан 200 метр ераклыкта гына рөхсәт ителә.

:: Авылларда гына түгел, шәһәрләрдә, шул исәптән Казанда да кыргый җәнлекләр шактый еш күренә башлады...

– Монысы да хайваннарның азык эзләп урманнардан чыгуына бәйле. Чүплекләрдә ризык әзер бит. Ләтчәләр гадәттә шәһәр янындагы бакчаларга елыша. Куяннар да агач үскән урыннарда күренә. Аңлашыла да инде: шәһәр зурая, бакчачылык ширкәтләре уртада калган очраклар да күп бит. Шәһәр кырыендагы агачлыклар эченә йортлар салына, урман киселеп, юллар төзелә. Димәк, кыргый хайваннар безнең биләмәгә түгел, без аларныкына керәбез булып чыга. Бу факторны да онытмаска кирәк.

Киңәш

• Кыргый хайваннар һөҗүм иткән очраклар булса, турыдан-туры Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Телефоны: **8(843) 211-70-78.**

• Кыргый хайваннар белән очрашырга туры килсә, аларны куркытырга, куалап җибәрергә яки ашатырга тырышмагыз. Бернинди дә ярдәм күтәрлек урын булмаса, читкәрәк китеп, **«112»** телефонына шалтыратудан да яхшысы булмас.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сәрия
МИФТАХОВА

УКЫГАН МЕҢНЕ ЕГАР

Илдар Мөхәммәтҗанов

20 июньдә югары уку йортларында кабул итү кампаниясе башланды. Быелгы абитуриентлар укырга кая керергә җыена? Киләчәктә нинди һөнәр сайлаганнар отачак? Түләүле бүлекләрдә бәяләр тешләшмиме? «ВТ» хәбәрчесе вузлардагы вазгыятьне белеште.

Кемгә – кирәк, кемгә – юк

Соңгы вакытта яшьләрдән: «Нигә кирәк инде бу югары белем? Техникум тәмамлап та эшкә урнашып була бит», – дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Әти-әниләр дә ул-кызларын, элеккеге кебек, соңгы үгезен суеп яки әҗәткә акча җыеп укыту яклы түгел. Балага һөнәрне көчләп тагарга ярамаганлыгын аңлый башладылар, ахры. Дипломның сандык төбендә саргаеп ятуы кемгә кирәк? Абитуриентлар да бер-берсенә ияреп, юрист, икътисадчы, укытучы булырга теләми. Техникум, көллиятләрдә һөнәр үзләштереп эшләү ягында алар хәзер. Әйтик, республикада 9 нчы сыйныфны тәмамлаучыларның яртысыннан артыгы урта һөнәри белем бирү йортларына китә. Әмма бу әле югары белемнең кыйммәте кимеде дигән сүз түгел икән. Һәрхәлдә, вузларда шулай дип аңлаттылар.

«Зарплата.ру» тикшеренү үзәге уздырган сораштыру күрсәткәнчә, илдә чыгарылыш укучыларының 76 проценты – югары белем, калганнары урта махсус белем алырга җыена. Респондентларның 14–15 проценты IT һәм медицина юнәлешләрен иң популяр дип саный. Шулай ук замана таләп иткән иң кирәкле белгечләр исәбенә юриспруденция, мәгариф (10 проценты), дәүләт хезмәте (8), хезмәт күрсәтү, финанс өлкәсен (6) керткәннәр. Сораштыруда катнашучылар фикеренчә, сәнгать, маркетинг һәм PR, мәдәният һәм сәнгать өлкәсе белән кызыксыну әллә ни зур түгел.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгында да, югары белемгә карата кызыксыну кимемәде, диделәр. Моны вузларга бүлеп бирелә торган бюджет урыннарыннан да күрергә мөмкин. Әйтик, быел республиканың югары уку йортларында шундый 20844 урын бар. Мәктәпне тәмамлаучы 11 нче сыйныф укучыларының саны исә 14 меңнән артык. Җитәрлекме, түгелме икәнлеген шуннан чамалагыз инде. Быел инженер-техник, педагогика юнәлешләренә бюджет урыннары күбрәк бирелгән.

Вузларда кызумы?

КФУда абитуриентлар агымын 1–10 июльдә көтәләр. Уку йортының кабул итү комиссиясе җаваплы сәркатибе Александр Бибик әйтүенчә, әлегә урта һөнәри уку йортларын һәм алдагы елларда мәктәпне тәмамлаган егет-кызлар гариза тапшыра. Арада быел аттестатны иртәрәк алучылар да бар. Кемнәрнеңдер әле имтихан нәтиҗәләре билгеле түгел. Хәзерге вакытта бакалавриат һәм магистратурага көндезге бүлеккә 21 мең гариза кабул иткәннәр. Шуларның 13 меңе – түләүле бүлеккә. Барлыгы 7300дән артык бюджет урыны бар.

– Абитуриентларның 86 проценты документларын онлайн тапшыра, – ди Александр Бибик. – Югары белем алуга карата яшьләрнең кызыксынуы кимемәде. Техникум, көллият тәмамлаган егет-кызлар укуын вузда дәвам итәргә тырыша. Конкурс зур. Узган ел бары инженер белгечлегенә барырга теләүчеләр генә азрак булды. Бу кайбер укучыларның физикадан БДИ сайламавына бәйле иде. Быел чыгарылыш укучылары арасында әлеге фәнне тапшыручылар күбрәк. Бюджет бүлегендә әлегә иң күп гаризалар халыкара мөнәсәбәтләр, икътисад һәм финанс, юридик факультет, психология һәм мәгариф, фундаменталь медицина һәм биология, инженерлык институтларына туры килә.

Казан илкүләм тикшеренүләр технология (КХТИ) университетының кабул итү комиссиясе җаваплы секретаре Ирек Шәрәпов белдергәнчә, соңгы елларда вузда инженерлык, нефтехимия юнәлешләрен сайлаучылар саны арткан. Хәзерге вакытта 1580 гариза кабул иткәннәр. Бюджет бүлегенең барлык формаларына 4249 урын бар. Вузда студентларның якынча өчтән бере түләүле бүлекләрдә белем ала. Быел төзелеш, мехатроника һәм робототехника кебек яңа юнәлешләр ачканнар. Яшьләрне күбрәк химия технологияләре һәм IT өлкә кызыксындыра.

Казан илкүләм тикшеренүләр техник (КАИ) университетка исә әлегә 500 гариза кергән. Монда авиатөзелеш, электроника, мәгълүмат технологияләренә бәйле белгечлекләргә сорау зур. Магистратурада – 800, бакалавриатта 1500гә якын бюджет урыны бар. Һәр елдагыча, гаризаларны Россиянең төрле төбәкләреннән, чит илләрдән, ә иң күбесе Татарстан абитуриентлары тапшыра.

Казан дәүләт энергетика университетына 1684 урын бүлеп бирелгән. Электроэнергетика һәм электротехника, җылылык энергетикасы һәм җылылык техникасы белгечлекләре һәм IT юнәлешләр популяр.

– Абитуриентларның югары белем алу теләге кимемәде, киресенчә, арта гына бара. Чөнки 10–11 сыйныфка югары белем алырга теләгән балалар килә, – дип белдерделәр уку йортының матбугат үзәгендә. – Энергетика өлкәсе перспективалы, бөтен төбәкләргә дә кирәк. Университет сәләтле абитуриентларны җәлеп итү буенча күп эшли. Аларны федераль олимпиадаларга әзерлибез. Без 70тән артык мәктәп белән эшлибез. Быел университет Россия Президенты грантын отты һәм без мәктәп укучылары өчен «һөнәргә старт» яңа белем бирү мәйданчыгы ачабыз. Олимпиада җиңүчеләре өчен университетта махсус программа бар. 1 нче курстан ук студентлар фән белән шөгыльләнә, грантларда, стартапларда катнаша. Алар тулай торакта үзләренә ошаган иң яхшы бүлмә сайлый ала һәм югары стипендия түләнә. 100дән артык предприятие белән килешү төзелгән. Практика узганнан соң студентларның яртысы әлеге предприятиеләрдә эшли.

Абитуриентлар нәрсә ди?

Әгерҗе районының Исәнбай мәктәбен тәмамлаган Камилә Ганиеваның хыялы – табибә булу. Химиядән БДИны – 100, рус телен – 91, биологияне 89 баллга тапшырган ул.

– Документларны Ижау һәм Казан вузларына тапшырачакмын. Еракка китәсе килми, – ди Камилә.

Балтач районында яшәүче Лилия Закирова кызы бюджет бүлегенә укырга керә алыр, дип өметләнә. Мәктәптә яхшы укыган, сынауларын да әйбәт балларга тапшырган. Энҗе геодезия өлкәсен сайламакчы. Читкә китү теләге юк.

– Югары уку йортына керү теләге бик көчле. БДИга әзерләнүдән бигрәк, психологик ягы авыр булды. Балаларда югары белем алу теләге кими бара, минемчә. Ни өчен дигәндә, күпләре БДИдан куркып, техникумнарга китә, – ди Лилия.

ТАТАРСТАН ВУЗЛАРЫНДА БЮДЖЕТ УРЫННАРЫ

- Педагогик белем – **2589**
- Информатика, исәпләү техникасы – **1788**
- Электр һәм җылылык энергетикасы – **1484**
- Химия технологияләре – **1237**
- Машина төзелеше – **1039**
- Физик культура – **770**
- Авыл, урман хуҗалыгы, балыкчылык – **734**

Түләүле уку

Казан Федераль Университеты
Иң кыйммәтлесе (дизайн юнәлеше) – **265** мең сум
Иң арзаны (яшьләр белән эшне оештыру) – **126** мең сум

Казан дәүләт медицина университеты
Иң кыйммәте
Дәвалау эше – **245** мең сум
Теш табибы – **248** мең сум
Педиатрия – **213** мең сум
Сәнәгать фармациясе – **169** мең сум
Иң арзаны
Социаль эш – **140** мең сум
Шәфкать туташлыгы эше – **158** мең сум

Казан дәүләт энергетика университеты
Иң кыйммәте
Электроника, нанотехнология; гамәли информатика, су биоресурслары һәм аквакультура, энергетика машина төзелеше – **138 300** сум
Иң арзаны
Икътисад, социология, гамәли математика, реклама һәм җәмгыятьчелек белән элемтәләр – **119 800** сум

Казан илкүләм тикшеренүләр технология (КХТИ) университеты
Иң кыйммәте
Дизайн – **288 600** сум
(Чит ил студентларына – **324** мең сум)
Нефть һәм газ эше – **201 600** сум
Наноинженерия – **207 600** сум
Электроэнергетика һәм электротехника – **169** мең сум
Иң арзаны
Икътисад, менеджмент – **141** мең сум
Гамәли математика – **144** мең сум

Казан дәүләт илкүләм техник университет (КАИ)
Иң кыйммәте
Авиатөзелеш юнәлеше – **185** мең сум
Техник физика – **180** мең сум
Программалы инженерия – **165** мең сум
(Чит ил гражданнары өчен – **205** мең сум)
Иң арзаны
Икътисад – **140** мең сум
Радиотехника; инфокоммуникацион технологияләр һәм элемтә системалары – **148** мең сум

ФӘНИЛӘ ИЛАЕВА:

«ЙӨРӘГЕМНЕ ЙОДРЫГЫМА КЫСЫП, АЛГА АТЛАДЫМ»

Фәнилә Илаеваның шәхси архивыннан

Аның язмышын тыңлаганда, күздән ирексездән яшь ага. Тамакка төер тыгыла. Ничә ел кеше язмышларын язып, бу юлы ул түгел, мин балавыз сыгам. Йөрәге тулы сагыш, әрнү булган ханым тизрәк мине юатырга ашыга. Чаллыда яшәүче 67 яшьлек Фәнилә Илаева үзенең көчле рухы белән сокландырды. Ирен, кызын, киявен, оныкларын югалткан анага үлем белән очрашырга туры килә.

Ялгызлык уты

Фәнилә белән Ринатны Казан таныштыра. Берсе – Бөгелмә кызы, икенчесе Лениногорск егете була алар. Ул чакта Фәнилә апа Казан дәүләт мәдәният институтында китапханәчеләр әзерләү бүлегендә укый. Ә Ринат абыйның Алмаз Хәмзин белән бергә укып, эшләп йөргән чаклары. Берсе җырлый, икенчесе баян уйный.

– Ринат инде студент чагында ук Зөһрә Сәхәбиевага, Хәйдәр Бигичевка баян уйнады. Мине исә «Саз» ансамбленә җырларга чакырдылар. Укыганда шушы ансамбльгә йөрдем. Ә инде кулга диплом алгач, әни ялгыз дип, Бөгелмәгә кайтып киттем. Ул чакта Ринат белән дуслашып йөри идек. Аны армиягә алдылар да юллар өзелде. Тик язмышыбыз уртак булган икән. Ул мине эзләп тапты. Бераз очрашып йөргәннән соң, гаилә кордык, – дип искә ала Фәнилә апа.

23 яшендә кияүгә чыга ул. Гаилә Чаллыда яши башлый. 1980 елны кызлары Гөлназ, ике елдан соң Лилияләре туа. Тик көннәрдән бер көнне түгәрәк гаиләнең бер чите кителә: ире 40 яше дә тулмаган килеш мәңгелеккә күзләрен йома.

– Ринатны күп җырчылар үзләренә эшкә чакыра иде. Мин дә дәүләт эшендә эшләгәч, ул гел гаиләне уйлады. Балаларны ташлап чыгып китә алмый идек бит инде, – ди Фәнилә апа. – Ринат баштарак ансамбльдә уйнап йөрде, аннан соң мәктәпкә эшкә күчкән иде. Берничә балага баян дәресләре дә укытты. 1994 ел иде бу. Ринат мәктәпкә укытырга килмәгән. Шуннан соң кече кызымны өйгә кайтарып җибәрәләр. Кайтып керсә, әтисе идәндә аунап ята. Ринатка инсульт булган. Декабрь башында таеп егылган иде ул. Ул чакта моңа әллә ни игътибар бирмәдек. Салкын тигән дип йөрдек. Йөзе дә шешенеп киткән иде. Баксаң, егылган җиргә кан җыелып, соңрак тамыр шартлаган. Шулай итеп 30 декабрьдә вафат булды, икенче көнне җирләдек...

Фәнилә апага бу чакта бик авыр була. Олы кызына – 14, кечесенә 12 генә яшь. Үзе исә 37сен дә тутырмый тол кала. Берни эшлисе килми аның. Тормышының яме сүнә.

– Урынымнан торып китим дисәм, аякларым мамыкка әйләнгән. Егылдым да төштем. Әнә шунда үз-үземә, йөрәгеңне йодрыгыңа кысып тот та алга атла, Фәнилә, дидем. Башкача мөмкин дә түгел иде, – ди ул. – Дөрес, эштән китеп елап ятып була иде. Тик балаларымны кеше итәсе бар. Ул чакларда хезмәт хакы юк, балаларның пенсияләрен дә түләмиләр иде. Ә яшәргә кирәк. Мин тормышны сайладым. Ике кызымны да Казанда укыттым. Башта кече кызым кияүгә чыкты, бер елдан – олысы. Бик матур гына гомер итә башладык.

Тагын хәсрәт

Лилия Минзәлә егетенә кияүгә чыга. Алар, әниләренә якын булыйк дип, Чаллыга кайтып төпләнәләр. Кызлары туа. Инде икенче сабыйлары туарга бер ай вакыт калган була. Минзәлә – Чаллы юлында фаҗигагә очрый алар. Берсе дә исән калмый.

– Бу вакытларны уйлыйм да, ничекләр түзә алдым икән, дим. Ирем хәсрәтен яңа гына кабул итә башлаган идем бит. Ә монда газиз балаларым салкын җир куенында ята. Өзгәләнде инде йөрәк... Еладым да, үксеп-үксеп әрнедем дә. Әгәр эшем булмаса, мин беткән идем. Яшәү теләгем бөтенләй юк иде. Җир белән күк арасында эленеп кенә торган чакларым иде. Шул чакта хезмәттәшләрем, дусларым, туганнарым ярдәмгә килде. 4 көннән эшкә чыгуымны сорадылар, – ди ул.

Чаллы мэриясенең матбугат үзәгендә эшләгән чагы. Икенче көнгә үк зур чара буласы. Ачы хәсрәт утында янмасын дип, хезмәттәшләре әнә шулай итеп кеше янына чыгара аны.

– Көндез эшләп кайтсам да, төнлә балаларым күз алдыма килә дә баса. Ике ел күземә йокы кермәде. Утым сүнмәде. Төне буе кроссворд чиштем. Шуннан соң сәламәтлегемнең начарлануын сизеп алдым. Кан анализларым начар булса да, үземә вакыт тапмадым. Көн-төн эштә идем. 2016 елда эштән киткәч, миңа диагноз куйдылар. Бавырым бик начарланган икән. Шуны дәвалар өчен көчле дарулар бирделәр. Ә алар сөякләремне йомшарткан. Әкрен генә умырткалыкларым сына башлаган. Ә мин авыртуга түзә алмыйча йөрим. Арка авырта дип, уколлар салдырдым, – ди Фәнилә апа.

«Гөлназымны югалткан идем»

Менә шул вакытта Гөлназның аягы авырта башлый. Берсе шешеп чыга. Фәнилә апа артык игътибар бирми. Укыганда сынган аягы үзен сиздертә, ахры, дип уйлый. Баксаң, Гөлназның аягында тромб өзелгән булган. Җитмәсә, шул аяк белән башта авылларында Сабан туе уздыралар, аннан соң балаларының сыйныфы белән бергә Кандракүлгә ялга китәләр.

– Гөлназның кан басымы төшеп беткәч, тиз генә «ашыгыч ярдәм» чакырталар. Аны Туймазы хастаханәсенә салалар. Икенче көнне без килгәндә, бөерләре дә эшләми иде инде. Мин үз авыруымны оныттым. Бар теләгем: кызым исән генә калсын. Өч баласы бар бит! Тиз арада кемне беләм, шуңа шалтырата башладым. Аллаһы Тәгалә ярдәме белән, Уфа һәм Казан табиблары ике сәгать эчендә баламның бөерен эшләтеп җибәрә алды, – дип сөйли Фәнилә апа.

Хастаханәдәге табиблар Фәнилә апаның сызлануын, начар йөрүен күреп алалар да тикшеренергә җибәрәләр. Баксаң, 8 умырткасы сынган килеш йөргән икән. Шулай да үзенә вакыт таба алмый ул. Өч ай буе өч оныгын карый. Гөлназ белән кияве гыйнвар аенда гына өйләренә кайталар. Бу вакытта Фәнилә апаның битләре дә саргаеп китә.

– Казанга җибәрделәр. Табиблар, бавыр күчереп утыртырга кирәк, диләр. Февраль ахырына язылып кайтып киттем. Килсәм, донор буласы кеше вафат булган. Тагын кайтып киттем. Бераздан тагын чакыртып алдылар. Бу юлы да өлгермәдек. Донорның гомере өзелде. Март аенда алдан Казанга килеп урнашырга булдым. Фатирга кергәч тә, табибка «мин килдем» дип хәбәр бирдем. Ике сәгатьтән чакыртып та алдылар. Ул көнне бик арыган идем. Уянып киткәндә, инде миңа кеше бавырын куйганнар иде, – дип сөйли Фәнилә апа.

Үзен бик тыныч тота ул. Табиблар да шакката. Үлемгә дә әзер идем, ди Фәнилә апа.

– Операциягә киткәнче, акчалар ваклатып куйдым. Исән калмаска да мөмкин идем бит. Күп итеп догалар укыдым. Аллаһы Тәгаләгә, Син мине бер дә ташламадың, бу юлы да булышсаң иде, дип теләдем. Табибларга да рәхмәт. Миңа табиб-онколог Александр Киршин белән Татарстанның хәзерге сәламәтлек саклау министры, хирург Марсель Миңнуллин гомер бүләк иттеләр, – ди Фәнилә апа. – Өч ел инде кеше бавыры белән яшим. Ул кешегә көн дә дога кылам. Урыны җәннәттә булса иде. Ә гомер бетмәгәч, яшисең икән. Сынаулар килде дип, якыннарымны югалттым дип кенә яшәүдән ваз кичеп булмый. Балаларым каберенә яңашәсендә урыным да бар минем. Тик анда үзең кереп ятып булмый бит. Һәр нәрсәнең – үз вакыты. Әле яшисем бар, димәк. Тормышны яратам мин. Ул да мине яратадыр инде!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Улымны терелтәсем килә!

Биектау районының Усад авылында гомер итүче Розалиянең иң зур теләге бу. Ике яшьлек улы Дамирның башка саусәламәт сабыйлар кебек үсүен тели ул. Тагын бер теләге – ире исәнимин килеш тизрәк махсус хәрби операциядән кайтсын.

– Улыбызны көткәндә бар анализларым да яхшы иде. Авыру бала табармын дип уйламадым да. Табиблар да кимчелек күрмәде. Тапкач, үзе суламады Дамир. Шул вакытта баш миенә зыян килгән, диделәр. 4 елдан артык көтеп алган балам җитлекмичә туды. Баштарак кимчелекләрен шуннан күрсәк, соңрак табиблар акылга зәгыйфь икәнен әйтте. Баламның башында тайпылышлар бар, – ди Розалия.

Шәрифуллиннар авыру балалары тугач, бик борчыла. Нәни сабыйларын кая гына йөртмиләр. Тизрәк терелтәселәре килә. Табиблар ялгышкандыр дип тә өметләнәләр. Тик анализ нәтиҗәләре алар сүзен раслый. Ир белән хатынга язмышлары белән килешергә кала.

– Узган елның 21 сентябрендә иремә махсус хәрби операциягә чакырып повестка килде. Ул чакта үз хәлемне үзем генә беләм. Бертуктаусыз еладым. Рашат миңа зур терәк иде. Бергә булганда, авырлыкларны да җиңелрәк күтәрә идек. Әмма бернишләп тә булмый. Ирләребез безне сакламаса, кем саклар? Әнә шулай дип тынычландым. Үземне кулга алып, балам хакына сабыр итәргә өйрәндем, – ди Розалия.

Дамирны табиблар җентекләп тикшерә. Төрле белгечләрнең фикере кирәк икән. Әмма кая гына барсалар да, баланың анализлары түләүле.

– Вакытында ачыкланган авыруларны дәвалау җиңелрәк, диләр. Шуңа да, тизрәк булсын өчен, түләүле табибларга барабыз. Безгә кирәкле анализларның берничә төрен бушка бөтенләй эшләмиләр. Генетик анализлар ул. Шушы көннәрдә ике төрлене бирәсе бар. Беренчесе – 35 мең, икенчесе 95 мең сум тора. Ирем дә янымда булмагач, акча күп тотыла. Каядыр бару өчен дә гел акча кирәк. Әле бит түләүле дә бар. Дәвалану курсларына да акча сорыйлар, – ди Розалия. – Газета аша ярдәм соравымның да сәбәбе шул. Тиешле анализларны тапшырып, баланың төгәлрәк диагнозын беләсебез килә. Аннары инде улымны тиешенчә дәвалый башлаячаклар. Шуңа күрә мәрхәмәтле кешеләрдән ярдәм сорыйм. Баламны бик тә терелтәсем килә. Ярдәм итсәгез иде.

Булышырга теләүчеләр өчен исәп-хисап реквизиты:

Шәрифуллина Розалия Искәндәр кызы исемендәге Саклык банкы картасы 89046613414 телефон номерына беркетелгән.

МАРАТ КӘБИРОВ:

«АНДЫЙ ӘСӘР БЕЗДӘ ЯЗЫЛА АЛМАС ИДЕ»

«Иң яхшы әсәрләр авылда языла», – дип әйтә иде Туфан абый Миңнуллин. Марат КӘБИРОВ та соңгы елларда авылда яшәүне сайлады бугай. Мөгаен, аның да иң яхшы әсәрләре авылда языладыр. Газета укучыларыбызны авыл тормышы белән дә таныштырып бара ул. Без аның белән сала тормышы, иҗат, китап һәм ил-көндәге хәлләр турында сөйләштек.

Анна Арахамия

:: Марат абый, соңгы елларда күбрәк авылда яшисең. Авылда иҗат итәргә уңайлыракмы әллә?

– Авылда еш булуның сәбәбе гади генә: туган нигезне тәртипкә китереп куярга кирәк. Анда гел яшәргә туры киләме, юкмы – анысын әлегә әйтәлмим. Авылда иреклерәк инде, табигатькә якынрак. Төрле интригалардан, кирәксез игътибардан читтәрәк. Гади кеше тормышы белән яшисең. Миңа шунысы ошый.

:: Иң яхшы әсәрләр авылда языла алайса?

– Языла инде монда. Яхшымы-яманмы икәнен генә бик чамалап булмый. Бераз чагыштырмача төшенчә бит инде ул.

:: Ничек яши соң авыл?

– Булдыра алганча.

:: Үлеп бара, дип әйтүләре дөресме?

– Алай дип әйтәсе килми... Элеккедәй гөрләп тә тормый инде. Тик барыбер яшәгән кеше яшәргә тырыша. Кемнәрдер читтә вахта ысулы белән эшли, кемнәрдер балта остасы булып йөри, кемдер мал асрап, кош-корт үрчетеп, умарта тотып, акча юнәтә. Һәркем кулыннан килгәнчә тырыша. Йорт-кураларга карап, начар яшиләр, бик интегеп торалар дип әйтерлек түгел. Тормышлары җитеш. Безнең халык тырыш бит инде ул. Булдырырга тырышып яши. Тик яшьләр юк. Авылда калырга атлыгып тормыйлар.

:: Авылның төп 5 проблемасын билгеләп карыйк әле.

– Эш урыннары юк, мәктәп юк, балалар бакчасы юк. Эш урыннары җитмәгәч, яшьләр кала алмый, яшьләр калмагач, балалар тумый, сабыйлар күп булмагач, балалар бакчасы һәм мәктәп эшләми. Авыруп китсәң, кая барып бәрелергә дә белмисең. Нәни бала үстергән кешегә бу бик авыр. Өлкән яшьтәге әти-әнисен карауачыга да шулай. Кибетләр, ял итү, күңел ачу урыннары турында сүз дә юк инде.

:: Аларны ничек хәл итеп була?

– Белмим. Беркем дә хәл итә алмый бит. Белүчеләр калмагандыр да инде хәзер.

:: Авылдашларың синең әсәрләреңне беләме? Кайсы да булса әсәрең буенча фикер алышканнары бармы?

– Җырларны беләләр. Җырлыйлар да бугай кайчагында. Газит-журналларда басылган кыска язмаларны укучылар күп шикелле. Күләмле әсәрләрне беләләр микән? Кызыксынганым юк бит. Калын китапларның кәгазь вариантын күргәннәре юктыр сыман тоела. Башкортстан бит инде бу... Минем Казанда чыккан китаплар монда кадәр килеп җитәлми инде, сатылып бетә. Интернеттан укыйлар бугай. Сиздереп-сиздереп куйганнары бар.

> Авыл кешесе китап укуын бик күрсәтеп барырга тырышмый. Ул күбрәк физик эш эшләве турында сөйләшә, печән әзерләү, мал карау, бакча үстерү ише нәрсәләрне. Шуларны сөйләгәч, башкалар күзендә бик эшлекле, уңган булып күренгән кебек тоела. Ә китап уку... Утлай эш өстендә китап укып утыру ялкаулык билгесе сыман.

:: Мин синнән күбрәкне көткән идем, дип әйтмиләрме соң?

– Әлегә әйткәннәре юк. Бәлки, артыгын көтмәгәннәрдер дә инде.

:: Бер язучы, хәзерге заманга кагылышлы әсәр язылмый, диган иде. Бәлки, син хәзерге заман турында әсәр язасыңдыр?

– Язучы да хаталана инде кайчагында... «Үсмерләр турында язучы юк», – дип әйтүчеләр дә бар әле ул. Ун еллар тирәсе элек мин дә шулайрак дип чыгыш ясаган идем. Шул чыгыштан соң гына игътибар иттем: үз әсәрләремнең күп өлеше үсмерләр турында булган икән. «Үсмерләр турында язучы юк, мин генә язам», – дип һаваланган, игътибар даулаган кебегрәк килеп чыкты. Гаепләүче булмады. Булса да, берни әйтәлмәс идем. Әле болай дип тиргәп ташларга да мөмкиннәр иде: «Нәрсә зарланасың? Үзең язучы бит, үз кулыңда бит, юк икән, булуын телисең икән – яз. В чем проблема?!»

Язуын яздым инде мин, башкалар да язды. Тик бүген дә кайбер язучылар һәртөрле мөнбәрләрдән: «Үсмерләр өчен язучылар юк», – дип сөйләнеп йөри. Юк дип әйтү һәр очракта да нәрсәнеңдер булмавын аңлатмый, кайчагында ул шулай дип әйтүченең чүт кенә надан кеше икәнлеген дә күрсәтә.

Бүгенге заман вакыйгаларына турыдан-туры кагылышлы әсәрләр миндә бар. «Тик син генә» – Казандагы 175 нче гимназия фаҗигасенә бәйле повесть, «Пандемия» – коронавирус матавыклары белән. Мин гел бүгенге чор турында язам бугай. Үткәннәр яки киләчәк сурәтләнгән әсәрләрдә дә – бүгенге заман чагылышы.

Бездә хәзер әдәби конкурслар бик матур традициягә әйләнеп бара. Шунда җиңгән әсәрләрнең дә күп өлеше бүгенгә чорны чагылдыра. «Казан утлары»нда хәзерге заман турында әсәрләр күп чыга. Айгөл Әхмәтгалиева хәтта Хәния Фәрхи турында бик матур роман да язып бастырды. Татар әдәбиятында хәзерге заманга игътибар юк дип әйтеп булмый инде.

:: Басылмаган китаплары басылганнарыннан күбрәк һәм популяррак булган берданбер язучыдыр син, мөгаен. Ничек уйлыйсың, киләчәктә электрон китаплар гына калачакмы?

– Икесе дә булыр. Һәрхәлдә, якын киләчәктә. Ә соңыннан электронга калыр. Бу инде безнең теләк-ихтыярга буйсына торган күренеш түгел. Аны берничек тә туктатып булмый. Бәлки, кирәкмидер дә. Электрон китапларның уңай яклары да, мөмкинлекләре дә күбрәк бит. Ул язучыны иреклe итә. Укучыны да. «Без бит Татарстаннан читтә яшибез, шуңа татар әдәбиятын белмибез», – дип әйтү хәзер наданлык кына түгел, аз гына ахмаклык та булып ишетелә. Әйтик, сез тәүлекнең теләсә кайсы вакытында минем теләсә кайсы электрон китапны сатып ала аласыз. Бүген язып бетерәм икән, аны сез иртәгә укый аласыз. Минекен генә түгел, бу өлкәдә эшләгән һәрбер язучыныкын. Шулай итәләр дә. Алалар, укыйлар. Электрон китаплар кешегә теләсә нинди әсәрне мизгел эчендә табып уку мөмкинлеге бирә. Бу – зур нәрсә. Элек мин, кирәкле китап эзләп, бер кибеттән икенчесенә чаба торган идем. Аннан китапханәләргә... Бу атналарга сузыла. Ә хәзер барысы да җайлы.

> «Электрон китапны кабул итә алмыйм, кәгазь китапның исен яратам», – дигән кешеләрне бик аңлап җитәлмим бугай. Әдәбиятны ярату – бер нәрсә, токсикомания – бөтенләй бүтән. Минем кәгазь форматта чыккан бик күп китаплар кыска вакыт эчендә сатылып бетеп бара. Тик укучылардан күп очракта фикер ишетелми. Шуңа күрә мин: «Укыр өчен аласызмы соң сез аны, таба астына куяр өченме?» – дип сорый идем. Кара әле, бәлки, аларны укырга дип түгел, ә иснәп ятарга дип алалардыр? Бәлки, әле берәр җирдә китап иснәүчеләр җәмгыяте дә бардыр... «Марат Кәбиров китапларын иснәүчеләр җәмгыяте», мәсәлән...

:: Алай да... Бу ясалма акыл дигәннәре тормышыбызга үтеп керсә, язучыга да эш калмас, мөгаен.

– Ясалма акыл тормышка үтеп керде инде ул. Калганы – вакыт эше генә. Әлегә калькулятор хәлендәрәк. Бухгалтерлар калькулятор кулланган шикелле бер зыянсыз файдаланып була торган. Тик аның мөмкинлекләре бик зур. Күз иярмәс тизлек белән үсә, камилләшә. Котылгысыз рәвештә үсә, чөнки кеше инде аннан берничек тә баш тарта алмаячак. Ясалма акылдан баш тартырга табигый ахмаклык комачаулый. Ә ясалма акылның нәрсәләргә сәләтле икәнен беркем дә, хәтта аны барлыкка китергән галимнәр үзләре дә төгәл әйтә алмый. Әгәр ул әдәби әсәрләр язарга өйрәнсә, чынлап та, язучыга эш бетә. Ялгышрак юнәлеш алса, кешенең үзен дә кысрыклап чыгарырга мөмкин, диләр. Беркем дә, бернәрсә дә мәңгелек түгел. Мин алай ук коточкыч булырына бик ышанмыйм инде. Язучы эшсез калыр дип тә уйламыйм. Әлбәттә, төрле сайтлар, интернет-кибетләр, социаль челтәрләр өчен текстлар язучыларны ул бүген үк алыштыра ала. Тик әдәбият – катлаулы өлкә, сюжет төзү, текст яза белү белән генә чикләнми, ул аз гына бүтән үлчәмдә.

:: Чит ил әдәбиятыннан нинди әсәр сиңа яңалык булды? Шундый әсәр бездә языла алыр идеме?

– Исемләп санап тормыйм инде, күп кенә... Юк, андый әсәрләр бездә языла алмас иде. Шул бүтән җирдә языла алмаганы өчен яңалык бит инде алар. Бөтен җирдә дә языла ала торган әсәрләр яңалык була алмый, чөнки ул темага барыбер кемдер алына, кемдер яза. Я Европада, я Азиядә, я икесендә дә берьюлы. Я уңышлырак, я хөртирәк итеп. Төрле әдәбиятларда бер үк теманы күтәреп, бер үк сюжетка корылган әсәрләр шунлыктан да хасил була торгандыр. Таптагалан темаларны да яңача яңгырата алучылар бар. Барысы да авторның талантыннан,

үзенчәлегеннән тора. Ә язучыны үзе яшәгән мохит формалаштыра – җирлек, дәвер, даирә. Нинди генә даһи булмасын, әйтик, гарәп язучысы «Собор Парижской богоматери» дигән роман яза алмый бит инде... Ниндидер әсәрнең тууы, нинди дәрәҗәдә булуы идарә итеп булмый торган бик күп төрле факторлардан тора. Ләкин иң беренче урында – авторның шәхесе һәм мохит.

:: Язучылык һәм гаилә. Иҗат тормыш алып барудан, бала тәрбияләүдән читләштерә, диләр. Синдә ничек булды? Тагын хатын аңласа һәм ярдәм итсә генә, яхшы әсәр язып була дип әйтәләр...

– Алай түгел инде ул. Хатының аңласа, ярдәм итсә әйбәт, әлбәттә, ул вакытта күңелең тыныч була, нәрсә эшләсәң дә уңышлы килеп чыгарга мөмкин. Килеп чыкмаска да мөмкин. Тик барыбер рәхәтрәк була, уңышсызлыгыңны уртаклашырлык таянычың бар. Яхшы гаилә – ярты бәхет бит инде ул.

Тик иҗат – һәрвакыт иҗат урынында. Гаиләсеннән уңмаган кешеләр арасында да бик әйбәт язучылар бар бит. Аннан соң, язучы бертуктаусыз язып кына утырмый ич инде. Язу сәнгате, гомумән, күп эшләүне, күп һөнәрләр белүне, күп халәтләр кичерүне таләп итә. Язучы берьюлы берничә кеше язмышы белән яши һәм үзе булып кала белергә тиеш. Соңгысы аеруча мөһим, үзлегеңне саклый алмасаң, акылдан шаштым дигән сүз бит инде. Бу, бер яктан, бик четерекле, икенче яктан, файдалы: башкаларны аңлый алырга мөмкинлек бирә.

> Иҗат мине гаиләдән, балалардан читләштерде дип әйтәлмим. Алар – минем мәхәббәтем, өметем, тормышымның мәгънәсе бит инде. Мин берсен дә читкә куймаска тырыштым. Икесе дә һәрвакыт үзенә тартып торды. Әлбәттә, гел теләгәнчә килеп чыкмагандыр инде. Тик бу мәсьәләдә мин бик бәхетле булдым. Яраткан эшең һәм яраткан кешең белән яшәү – зур бәхет ул.

:: Иң зур теләгең нинди?

– Теләкләр күп, кайсы зуррак, кайсы кечкенәрәк икәнен генә әйтәлмим – кем чагыштырып утырган инде аларны. Тормышка ашканчы һәр теләк зур булып тоела. Мин халкымның хөр булуын телим, дәүләтле булуын. Бу дежур сүз түгел: зур һәм көчле милләтнең язучысы гына зур мәйданга чыга ала. Авылда гына түгел, дөнья аренасында да кем баласы булуыңа карыйлар. Аз гына күренә башладыңмы, шундыйрак сорау калкып чыга: «Кем баласы бу, кайсы дәүләт, кайсы милләтнеке?» Мин мәктәпләрдә татар балаларын үз телендә укытуларын телим. Язган әсәрләремнең әйбәт булуын, аларны укучылар күп булуын телим. Илгә-көнгә тынычлык телим. Яуга киткән солдатларны күз алдына китерсәм дә, аларны көткән ата-аналарын, гаиләләрен уйласам да, җан чымырдап куя. Монысын Россияне генә түгел, бөтен дөньяны күзаллап әйтәм: Ходай ахмак хакимнәргә акыл бирсен, акыл кермәстәйләреннән азат итсен. Теләкләр бетәсе түгел... Кайсы зуррак соң? Үзегезгә ошаганын сайлап алыгыз да сез дә кушылыгыз, бәлки, кабул булыр.

:: Мөмкинлек бирелсә, тормышыңда нәрсәне үзгәртер идең?

– Белмим. И-и-и, мин әллә нәрсәләрне үзгәртеп карадым инде, бер файдасы да тимәде. Хәзер, бәлки, кирәкмидер дә инде. Барысы да шул хәлдә калсындыр. Бер карасаң, артык үкенечле гомер түгел бит инде бу.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ГҮЗӘЛ ӘДҺӘМ

ҖИЛӘК ТӘМЕ

(ХИКӘЯ)

– Алсу!

Кызчыкның керфекләре дерелдәп куйды. Күзләре кинәт сызык кына булып ачылды да, өстенә иелгән хатынны күреп алуга, ул елмаеп җибәрде. Әле яңа гына мендәр читендә сулып яткан хәлсез кулларына да җан керде кебек, очарга җыенган каз канатларыдай талпынып, хатынга тартылды.

– Әни! Әнием!

Өйдәгеләр бу хәлдән өнсез калды. Зиннур да, әтисе үзе дә бу галәмәттән каушап һәм аптырап аларга төбәлде.

Я, нәрсә эшләргә тиеш иде соң алар?

«Ул синең әниең түгел!» – дип, таныш түгел хатынның күкрәгенә сеңгән сабыйны йолкып алыргамы?

Үзе! Үзе эзләп, юллап алып кайтты Дамир бу хатынны йортка!

...Алсуны, эче авыртып, район хастаханәсенә алып барганнар иде. Диагнозны тиз куйдылар: сукыр эчәк! Операциядән соң атнадан артык больницада ятты Алсу. Авылдан районга кадәр – ун чакрым. Әтисе көн-төн эштә, урып-җыюга әзерлек, дип чабып йөргән көннәре. Зиннур үзе дә йорт мәшәкатьләреннән арына алмады, яшелчәсе-бакчасы дигәндәй, тавык-чебешләре, сыеры-бозавы... Авылда эш бетәмени! Алсу янына һәркөн бара алмасалар да, кучтәнәчен-мазарын гел җибәреп тордылар. Район үзәгендә яшәүче авылдашлары да кызчыкны онытмады.

Менә Алсулары хәзер өйдә. Ябыгып, суырылып кайтты кызчык хастаханәдән.

«Күгәрчен кебек кенә калган!» – дип уйлады Дамир, эчтән сыкрап. – Аллага шөкер, кызчыкны үлем тырнагыннан алып калды район врачлары. Иң мөһиме – шул!»

Әмма кызчык бик үзгәреп кайткан иде, көне буе «әни» дә «әни» дип бытылдады, ә кичкә таба «әни»не таптырып, тавыш куптарды. Баштарак көйсезләнү булып яңгыраган «Әни кайда?» сүзе тора-бара үксү, ярсу белән алышынды. Өйдәге ике ир-ат – Дамир белән Зиннур дүрт яшьлек Алсуны ничек тынычландырырга белми изаланды. Нинди әни турында сөйләнә соң бу бала? Алсу кемне таптыра?

Чынлыкта, кызчык әнисен белми иде. Әниләре үлгәндә, Алсуга ике генә яшь иде шул әле. Сабый хәтере ул чакта әни юклыгына тиз ияләште кебек. Әллә ни юксынмады да сымак. Дөрес, баштарак ул елады, әмма тора-бара тынычланды. Инде менә күнекте, ияләште дигәндә генә...

Кызчык төне буе көйсезләнеп чыкты, кулдан төшмәде, ярсый-ярсый үксеп, үкереп, берәүгә дә йокы бирмәде. Юатырга маташулар – барысы да юкка! Таңга таба ул бөтенләй хәлсезләнеп таралып төште. Әллә йокыга китүе булды, әллә аңын ук югалтты инде? Кипкән иреннәре генә вакыт-вакыт: «Әни... Әни...» – дип сулкылдап, исәнләген сиздереп торды.

Дамир киткәч, Алсу янында Зиннур берүзе калды. Бераздан кызчык та уянды. «Ярый әле еламый!» – дип, шатланырга гына өлгерде малай, әллә күз тидерде инде! – Менә тотынды акырырга! Туктатырмын да димә! Бөтен тәне ут янган балага, аптырагач, авылдагы фельдшерны чакырырга туры килде.

«Әни!» дә «әни!»...

Өченче көн дигәндә, түземе беткән Дамир, матаена атланып, районга чапты. Аны аңладылар, йокы сәгате якынлашып килсә дә, Алсу яткан палатага уздырдылар...

Биш кешелек бүлмәдә Алсуның караваты әле дә буш тора иде. Башка дүрт ятакта – балаларын кочкан дүрт ана. Алар хәлне бик тиз төшенеп алды. Әйе, Алсу монда да көйсезләнгән икән. Аның сабый күңеле бер тигезсезлекне һич кенә дә төшенеп җитә алмаган: «Нигә башка балалар әниләре белән ята да, ә ул – берүзе? Ә минем әни кайда?» – дип елаган кызчык. Менә аңлатып кара син дүрт яше дә тулмаган сабыйга тормышның шушы хакыйкатен! Шундый чакта (рәхмәт яугыры дими ни дисең!) юатучы кешесе дә табылган. Идән юып йөргән санитарка хатын кызчыкны күтәреп алган, иркәләгән, әкият тә сөйләгән, хәтта төннәрен дә аның янында кунып калган. Кочаклашып икәү йоклаган алар. Бала хатынга көннән-көн ияләшә барган, бүтәннәрдән күреп, «әни» дип тә дәшә башлаган. «Әни! Нинди матур, ягымлы сүз икән ул! Һәм... яңа сүз!»

Хатын Сания исемле икән...

Санияне тәки эзләп тапты Дамир. Әллә ни еракта да түгел, күрше авылда гына ялгыз башы яшәп ята икән. Авылда эш булмагач, районга йөреп эшләп йөргән көннәре, ди.

– Бала өзлегеп китәр дип куркам... Ни йокысы, ни тынычлыгы юк... Кайтканнан бирле тамагына да берни капмый... Бераз хәлләнгәнче янәшәсендә булсагыз, дим...

...Менә хәзер шул хатын аларда утыра.

Дамир үзе ниләр уйлагандыр, әмма Зиннур Санияне бер күрүдән үк яратмады. Чит, ят иде бу хатын малай өчен. Әнисе хатирәсе әле бик тә, бик тә яңа иде шул. Ике ел! Бер уйласаң, күпме көннәр үткән! Әмма Зиннур өчен әниле һәр көн, һәр мизгел күңел түрендә шундый итеп сеңеп калган... Мең ел үтсә дә, ул хатирәләр бер тамчы да тоныкланмас кебек, отыры яңарып, тагын да мулрак төсмерләргә баеп, калкып чыгар күк тоела аңа.

Әнисенең күзләре кара иде Зиннурның! Кара кашлы, кара күзле иде ул. Ә бу хатынның күзләре зәп-зәңгәр булып чекерәеп тора. Җитмәсә, бит уртасында кап-кара миңе дә бар. Анысы бигрәк тә килешсез һәм шыксыз тоелды малайга. «Үзенеке дә түгелдер әле. Ясалган миңдер! Хәзер, акча түләп, әллә ниләр ясаталар ла!» Шуны гына аңламыймыни Зиннур?!

Ә менә үз әнисенең миңнәре... Алар бишәү иде... Миңле иде Зиннурның әнисе. Исеме дә Миңленур иде аның! Малай, бармаклары белән төртә-төртә, шул миңнәрне санарга ярата иде... Иягендә – берсе... Ә колак янында – өлгергән шомырттай эленеп торганы – тагын берәү... Өченче-дүртенчесе исә, игезәк мәк орлыгыдай янәшә булып, борын яфрагын бизәп тора. Ә иң зур матур миңе ике каш арасында балкый. Кинодагы һинд кызлары көнләшерлек! Дөньяда аның әнисе кебек чибәр бүтән берәр хатын булды микән?

...Бу хатынның исә бөтен битен сипкел баскан. Кер сабыны белән ышкып-ышкып юасы килә үзен. «Чәчен дә әйтер идем... Меринос сарык йоны төсле бөдрәләнеп тора... Ә буе... Буе колга кебек!

Зиннур йодрыкларын кысып куйды. Алсуын күр инде, шул хатынны чытырдатып кочкан да, «әни!», «әни!», дип тәтелдәвен белә.

«Хыянәтче! Әнине шушы хатынга алмаштырган бит!»

Шул секундтан Зиннур, Санияне генә түгел, нәни Алсуны да күралмас булды. Сеңлесенең әле бик кечкенә икәнен, дүртенче яшен яңа гына тутырып килүен дә аңлый бит югыйсә! Әмма болар барысы да әллә ни әһәмияте булмаган бер нәрсә кебек кенә тоелды аңа.

«Хыянәтче! Әнине оныткан!»

Ул көнне йортка тынычлык инде. Алсуның чырык-чырык көлүе өйне ямьләп, күңелләрне күтәреп җибәрде. Зиннур үзе дә чит бер хатынның алар мохитендә пәйда булуына ияләшә башлады дисә, шушы бөтенлекне чәлпәрәмә китергән бер вакыйга булып алды.

Соңгы елларда сыер саву вазыйфасы Зиннурга йөкләнгән иде. Тиз үзләштерде бу эшне малай. Аның нәрсәсе бар! Сыерлары Иркә бик ипле, ягымлы мал: сауганда типми дә, дуламый да.

– Сыер сауганда, башыңа яулык бәйлисеңме? – дип мыскыллап көлгән күрше малае Илдарның да авызын тиз томалады Зиннур.

– Авылдагы сыер комплексында әнә савымчыларның яртысы – егетләр! Шулардан барып сора!

Кичен Иркәне саварга чыгам дисә, чиләген табалмый җәфаланды ул.

«Кая китте икән соң? Югыйсә иртән, чиләкне юып, шушы киштәгә кую гадәткә кергән лә!»

Нәкъ шул минутта, чиләк белән сөт күтәреп, Алсуны иярткән Сания абзардан килеп чыкмасынмы!

– Тик торганчы, бер эш булыр дип, сыерны сауган идем! Бирәк ипле мал икән, рәхмәт яугыры!

– Абыем, күрәсеңме! Иркә безгә күпме сөт бирде!

Зиннур телсез калды. Күңел түрендә дулаган давыл-бураннарны тыя алмыйча, ул тагын йодрыкларын йомарлады. Ахырдан түзмәде:

– Нигә кидең? Ни хакың бар? – дип кычкырып, аптыраган хатын өстендәге халатны тарткалый-йолыккалый башлады.

– Сал! Бу – әни халаты! Әнинеке!

Зәңгәргә кара төртке төшкән халатны сыер сауганда кия иде Миңленур. Аның җылысын саклап торган халат бит ул! Шул җылыга уралып, рәхәтенә төренеп, хәтердә сакланып калган әнисе сурәтен тоемлап, аның күңелгә сеңгән мөлаем карашыннан оеп сава иде Зиннур Иркәне. Ә бу хатын... Бу хатын шул рәхәтлекне имгәткән! Аңа бәреп кереп, малайны рәнҗеткән!

...Ул төнне Зиннур печәнлектә үткәрде.

«Минем хәзер берәүгә дә кирәгем юк! Әтигә дә, Алсуга да... Бөтенесенең шул Саниягә ушы киткән! Алсуның ят хатынга чытырдап ябышуы гына җитмәгән, әтисе булып әтисе! – шуңа ярарга тырышып йөри!»

Әнә тагын Зиннурны юмалап маташа:

– Улым, алай пырдымсыз кыланма инде... Алсу терелгәнче, Сания апаң аның янәшәсендә торса, шәп булыр иде бит. Алсу хакына дип, әнә отпускасын да көйләде... Тизрәк терелсен иде балакай...

Ул чакта дәшмәгән иде Зиннур. Ризалашырга туры килде. Ничек каршы киләсең ди?! Аның кечкенә сеңлесе бит Алсу! Нәкъ әнисе кебек! Борын яфрагына кунган мәк орлыгыдай игезәк миңле кызчык бит ул!

...Атна-ун көн үтеп тә китте. Алсуның көр тавышы өйгә генә сыешмыйча, ишегалдын да тутырды, урамда да яңгырый башлады.

– Әни, әнием! Чебиләрне бергәләп ашатыйк!

– Мин дә кыярларга су сибәм!

– Әни! Кош телен мин дә пешерәм!

Дәвамы бар >

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
медицина тикшеренүе узу өчен
СЕРТИФИКАТ уйната

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның
икенче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язылу

П2435 – җомга саны
512 сум 70 тиен
П2409 –
атнага дүрт тапкыр чыга
1227 сум 30 тиен

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН
БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040 info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘК ОТ!
Сертификатлар:
1) 9 төрле УЗИ+уролог консультациясе;
2) 9 төрле УЗИ+гинеколог консультациясе;
3) остеопат ярдәме.

Тулырак сайтта: vatantat.ru

Акция 2023 елның 28 апреленнән башлап 30 июнәнә кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Реклама 16+

МЦ «НУРМЕД»
«Сәламәт хатын-кыз»
*АКЦИЯ ~~5 100 сум~~ 3 100 сум
(843) 246-76-00
(843) 209-19-29
Анализлар. Кече оча әгъзаларына УЗИ.
Сөт бизләренә УЗИ. Гинеколог консультациясе.
*Акция 2023 елның 30 июнена кадәр дәвам итә.
Адрес:
Салих Батыев ур., 1 йорт
Тулырак сайтта: nhkrt.ru
ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШҮ СОРАЛА.
Реклама 18+



Әз-мәз мәзәк

Без ике улыбызны бертигез яратабыз. Русланны да, тегесен дә.

* * *

– Мин бу эшне булдыра алмам, дип куркам.
– «Курку» сүзен оныт.
– Мин бу эшне булдыра алмам.

* * *

Шыгрым тулы автобуста хатын-кыз тавышы:
– Әй, абзый, нишлисез сез???
Тынлык.
– Нишлисез, дим?!
Тынлык.
Бөтен автобус:
– Абзый, әйт инде, безгә дә кызык бит.

* * *

– Вәлиев! Ник йөзең шешенгән?
– Бүген төнге өчкә кадәр йокының файдасы турында документаль фильм карадым.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Сара, башак, Труд, чара, Илүзә, Ми, Илһам, әр, таз, икс, Фаяз, алаша, иза, АМО, тургай, аракы, Миләүшә, уф, ат, Рая, Наил, ят, Ка, Алинә, Атлас, Имәни, ни, үт, Сиринә.

Вертикаль: Иа, Амур, ашамлыклар, фаялит, Самат, ятим, атаман, шок, Нәс, им, Фа, ым, әни, ир, БДИ, Яруллин, алтын, Шәүкәт, игәү, Рауза, шалкан, Күәм, Аймәт, Асия.

Беләсең килсә...

1 Кения башкаласы:
а) Найроби;
б) Джибути;
в) Триполи.

2 Татар телендә нәшер ителүче бу сатирик журнал 2014–2017 елларда Оренбургта чыккан:
а) «Шакмак»;
б) «Уймак»;
в) «Кармак».

3 Дима Билан тәхәллүсе белән чыгыш ясаучы җырчының чын исеме:
а) Виктор Билан;
б) Виктор Белан;
в) Виктор Билайн.

4 Бу илбашы 2 яшеннән 7 яшенә кадәр Казанда яшәгән:
а) Михаил Горбачев;
б) Борис Ельцин;
в) Дмитрий Медведев.

Җаваплар: 1. а); 2. в); 3. б); 4. б).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 14253 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 291

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+